КАДЕРЛЕ СУМ

«ВТ» хәбәрчесе акча җыярга комачаулаган гадәтләрне барлады

> 6

САУ БУЛ, ДАНИС!

Легендар хоккейчының саубуллашу матчыннан соң туган фикерләр

> 16

ЗИФА НАГАЕВА:

«Хәзер моңны акча дигәнең төртеп екты»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 115 (29082) | Җомга | 11 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

СУСАУ

ШӘҺӘРДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘР ГЕНӘ ТҮГЕЛ, АВЫЛ ХАЛКЫ ДА ЧИСТА СУСЫЗ ИНТЕГӘ

Җәен республикада су мәсьәләсе аеруча нык баш калкыта. Кайбер авыллар бер тамчы суга интексә, икенчеләре аның сыйфатыннан зар елый. Галимнәр исә эчкән суның сәламәтлеккә йогынтысы зур булуын раслый. Кайсы район халкы нинди су эчә? Без шуны ачыкладык.

> 5

Ишетми калмагыз

Россиядә күпбалалы ата-аналарга дүрт көнлек эш атнасы кертмәкчеләр. Леонид Слуцкий җитәкчелегендәге ЛДПР фракциясе шундый тәкъдим белән чыккан. «Известия» язганча, закон проекты Россия Хөкүмәтенә фикер алышуга җибәрелгән. «Өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә өстәмә буш вакыт тәрбия, сәламәтлек мәсьәләләренә күбрәк игътибар итү мөмкинлеге тудырачак», – дигән Слуцкий. Шул ук вакытта кыскартылган эш атнасын 18 яшькә кадәр балалары булган (төпчегенә 14 яшь тулганчы) ата-аналарга билгеләү зарурилыгы күздә тотыла. Депутатлар хезмәт хакын да биш көн эшләүчеләрнеке күләмендә калдыруны хуп күрә. Алар фикеренчә, күп бала тәрбияләү күп вакыт һәм тырышлык сорый, эш атнасы кыскарса, ата-аналарга балалары белән аралашу өчен вакыт күбрәк булачак.

Ел башыннан бирле Татарстанда, юлда баручы машинаның каршы як полосага чыгуы сәбәпле, 50 кешенең гомере өзелгән. Дәүләт автомобиль инспекциясе хәбәр иткәнчә, 157 һәлакәт очрагы шуңа бәйле. 244 кеше зыян күргән.

Автоинспекторлар искәртеп үткәнчә, каршы як полосага кергәнче, мондый дуамаллыкның нәрсә белән тәмамланачагын уйларга кирәк. Зур тизлектә чабу исә бигрәк тә аянычлы тәгәлләнергә мөмкин.

Узып китү кагыйдәләрен бозган өчен 5 мең сумга кадәр штраф яки 6 айга кадәр машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм итү каралган. Кагыйдәне кабат бозган өчен инде 1 елга «права»сыз калу куркынычы яный.

Республикада ятимнәр кими. Соңгы 3 елда аларның саны 1000гә, ягъни 10 процентка азайган. Мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта мондый балалар саны – 9257. Татарстанда яшәүче малай-кызларның гомуми санының 1 проценты бу.

Ел башына алынган мәгълүматлар буенча, 8671 бала (ятимнәрнең 94 проценты) гаиләләргә сыендырылган. 4034 бала опекун гаиләләрдә тәрбияләнә, 2544е уллыкка (кызлыкка) алынган.

Узган ел 128 бала үзләренең әти-әниләренә кире кайтарылган. Түбән Кама, Чистай районнарына, Казанның Киров районына гына да барлыгы 21 малай һәм кызны кайтарганнар.

Чамасы кыздыра. Ял көннәрендә дә шундый ук бик эссе һәм коры һава саклана. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, шимбә – 12 август һәм якшәмбе – 13 августта көндез термометрның терекөмеш баганасы +26…+32 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә +8…+14, көнбатыш районнарда +18 градуска кадәр. Явым-төшем көтелми. Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, киләсе атнада да салкынча һавага өметләнеп булмый әле. Атна башында – 14, 15 августта янә бик кызу булачак: һава температурасы +27…+32 градус чикләрендә тирбәләчәк. Сишәмбе – 15 августта урыны белән кыска вакытлы яңгыр көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Буа

Махсус хәрби операциядә катнашучы Андрей кайчандыр үзе укыган Боерган мәктәбендә бер сыйныфны ремонтлау өчен акча биргән. Яңа уку елына бүлмәнең диварларын, идәнен, парталарны буяганнар, челтәр һәм пәрдәләр сатып алганнар. Аның элеккеге сыйныф җитәкчесе Надежда Никонова әйтүенчә, Андрей сыйныфтагы мебельне дә алыштырырга теләгән, әмма укытучы мондый зур бүләкне кабул итмәгән. Чөнки башкарганы да – зур эш. «Безнең Андрей – яшьләр өчен бөтен яктан үрнәк: ул һәрвакытта да нык холкы, кыюлыгы һәм гаделлеге белән аерылып торды», – ди Надежда Никонова, укучысы белән горурланып.
(«Татар-информ»)

Зәй

Район укучыларын транспорт белән йөртүне оештыруга 8094000 сум акча бүлеп бирү планлаштырыла. Бу хакта документ дәүләт сатып алулары сайтында урнаштырылган. Зәйнең 1, 5, 6, 7 нче мәктәпләре һәм татар гимназиясе, шулай ук Бигеш, Югары Мәлем, Ал. Бистәсе, Бохарай, Югары Шепкә, Кадер, Түбән Биш, Поручик, Сәвәләй, Сарсаз-Баграж, Чыбыклы авыл мәктәпләре укучыларын транспортта йөртү оештырылачак.
(«Зәй яңалыклары»)

Балык Бистәсе

19 августта Балык Бистәсе районында беренче тапкыр хатын-кызлар халык кәсебенең «Бистә шәле» I республика фестивале узачак. Борынгы заманнардан Балык Бистәсе районы үзенең мамык шәлләре белән дан тота. Капка төбендә үк кунакларны театральләштерелгән тамаша белән каршы алачаклар. Төп мәйданга алып баручы юл үзе үк бу бәйрәм атмосферасын күрсәтеп торачак. Фестивальдә «Бистә ярминкәсе» оста куллар ярминкәсе, «Иң креатив шәл», «Шәлне иң тиз бәйләүче» бәйгеләре, остаханәләр, презентацияләр дә узачак. Моннан тыш, фотозона, музей зонасы, «БалаЧак» балалар уен мәйданчыгы эшләячәк. Чара ахырында мәйдан уртасына фестивальдә бәйләнгән иң зур шәлне алып чыгачаклар.
(Татарстан Мәдәният министрлыгының матбугат хезмәте)

Әлки

Район мәдәният йортында Татар Борнаенда туып-үскән җырчының – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Мирсәет Сөнгатуллинның – 70 яшьлек юбилее уңаеннан иҗат кичәсе узды. «Сез моңлы тавышыгыз, иҗатыгыз белән Әлки районын бөтен илгә таныттыгыз. Сезгә иҗат чишмәләрегезне саекмыйча халык мәхәббәтен тоеп, озак еллар хезмәт итәргә язсын, – диде район башлыгы урынбасары Рәшит Билалов Мирсәет Сөнгатуллинны котлаганда. Танылган җырчының Казандагы юбилей кичәсе 8 октябрьдә Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе залында узачак.
(«Әлки хәбәрләре»)

БЕЗНЕҢ ҖИР


tatarstan.ru

Кырымның хәзер үз Казаны бар. Кичә биредәге Форос бистәсендә яңартылган клуб белән «Казан» скверы ачылды. Төзү, яңарту эшләре Татарстан ярдәме белән башкарылган. Бистә халкының шатлыгын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та уртаклашты.

«Казан скверы» республика балалары ял итә торган «Сәләт-Ак Барс» яшьләр үзәге янәшәсендә урнашкан. Анда заманча спорт мәйданчыклары, ял зоналары урын алган. Яңа скверда мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен дә тиешле шартлар тудырылган.

Төзекләндерелгән клуб бинасы да бистә халкының иң яраткан урыннарының берсенә әверелер дип көтелә. Биредә түгәрәкләр эшләячәк. Моннан тыш монда күпсанлы мәдәни чаралар, мастер-класслар да уздырырга җыеналар. Клуб заманча техника белән җиһазландырылган.

Бу эшләрнең барысы да Татарстан ярдәме белән башкарылган. 2021 елда Ялта шәһәре администрациясе башлыгы Янина Павленко, төзекләндерү эшләрендә ярдәм итүне сорап, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать иткән иде. Әле кайчан гына хыялда булган эшләр шул рәвешле ике ел эчендә чынбарлыкка әверелгән.

Бистә халкының шатлыгын уртакларга килгән Рөстәм Миңнеханов Форосның алга таба да чәчәк атуын теләде.

– Сезне чын күңелдән тәбрик итәм. Биредә бик яхшы комплекс, матур сквер пәйда булды. Монда бар да бик яхшы оештырылган. Бу җир безгә бик якын. Монда ял итүчеләр арасында Татарстаннан килүчеләр дә байтак. Форос алга таба да чәчәк атсын! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Кырым башлыгы Сергей Аксенов, үз чиратында, Рөстәм Миңнехановка, клуб һәм скверны яңартуга көче кергән һәркемгә рәхмәт сүзләре җиткерде.

– Рөстәм Нургали улына һәм аның командасына, Татарстанга шундый зур эш башкарганнары өчен зур рәхмәт әйтәсем килә. Кырым язының беренче көннәреннән үк ике төбәк арасында туганнарча мөнәсәбәт урнашты һәм бу уртак эшләрдә дә чагыла, – диде Сергей Аксенов.

Кырым башлыгының сүзләрен Янина Павленко да куәтләде. Рәхмәт сүзләре җиткергәндә, Кырым белән Татарстан арасындагы хезмәттәшлекне ныгыту кысасында Казан белән Ялта шәһәрләре арасында да хезмәттәшлек турында килешү имзалануын телгә алды ул.

– Хәзер Казанда «Форос» скверы ачылуын көтәбез инде, – диде Янина Павленко.

КИЛӘЧӘК ҺӨНӘРЕ

Башкаладагы 6 нчы гимназиянең 8 нче сыйныф укучысы Булат Нургалиев киләчәктә кайсы тармакта эшләячәген яхшы белә. Пилотсыз авиацияне үз итә ул. Кызыксынып кына калмый, дроннар җыю белән дә мавыга. Аларның беренчесен 11 яшендә үк ясаган ул. Хәзер егетне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та белә.

Быел Булат пилотсыз авиация буенча илкүләм ярышта катнашып, югары күрсәткечләргә дә ирешкән. Әлеге ярыш «Архипелаг-2023» проект-белем бирү интенсивы кысасында үткәрелде. Булат анда иң яшь пилотсыз очу аппараты операторы дип табылган. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашу барышында бәйгедә алган хис-кичерешләре белән уртаклашты ул.

– Мин пилотсыз авиация системаларын куллану буенча компетенциядә катнаштым. Бу – бүгенге хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган иң катлаулы юнәлешләрнең берсе. Миңа инде хәзердән үк төрле федераль оешмалардан хезмәттәшлек турында тәкъдимнәр килә. Әмма минем киләчәк планнарым Татарстанга бәйле, – ди Булат.

Пилотсыз авиация буенча ярышлар 28 июльдән 7 августка кадәр Новосибирск шәһәрендә узды. Анда 85 төбәктән 1,6 мең кеше катнашкан. Татарстан данын исә 14 укучы һәм студент яклады. Алар 22 дисциплина буенча 13 алтын, 9 көмеш һәм 7 бронза медаль яулады.

Рөстәм Миңнеханов җиңүче егет-кызлар белән очрашуда Татарстан командасының чыгышын югары бәяләде.

– Без сезнең уңышларыгызга чын күңелдән шатланабыз. Һәр медаль җитди көндәшлек шартларында алынган. 85 төбәктән 1,6 меңнән артык катнашучы, көчле командалар булган. Шуңа карамастан, сез бик лаеклы чыгыш ясадыгыз. Без яңа җиңүләрегезне көтәбез, сезгә бар яклап ярдәм итәчәкбез, – диде Татарстан Рәисе.

Рөстәм Миңнеханов Татарстанның һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия) белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итүен дә билгеләп үтте.

– Роберт Уразовка аерым рәхмәт әйтәсем килә. Ул ярыш һәм һөнәри компетенцияләр ягыннан безнең республикага бик нык ярдәм итте. Без бергәләп Ворлдскиллс юнәлешен үзләштердек һәм 2019 елда Казанда һөнәри осталык буенча иң яхшы дөнья чемпионатын үткәрдек. Миңа калса, сезнең җиңүегездә Ворлдскиллс барышында алынган белем-күнекмәләрнең дә өлеше зур. Без бу эшне системалы рәвештә дәвам итәргә тиеш, – диде Татарстан Рәисе.

Роберт Уразов, үз чиратында, пилотсыз авиация буенча ярышларның ел саен үткәреләчәген хәбәр итте.

– Бүген бу – илдә дә, дөньяда да иң тиз үсә торган тармак. Ярышлар барышында сез бик файдалы тәҗрибә алуыгызга ышанам. Пилотсыз авиация өлкәсендә эшләү бүген иң өметлесе санала. Ул күктә генә түгел, ә программалаштыру, яңа материаллар – киләчәк икътисадын булдырачак барлык нәрсәләр буенча күнекмәләр алырга мөмкинлек бирә, – диде Роберт Уразов.

Һәрбер кирпече – сезнең кул көче

13 август – Төзүчеләр көне. Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин төзүчеләрне һәм тармак ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан котлады.

«Бу бәйрәм республикада яшәүче 92 меңнән артыграк кешегә кагыла: төзелештә һәм катнаш тармакларда нәкъ менә шуның кадәр кеше эшли, – диелә котлауда. – Сез сайлаган һөнәр – нәтиҗәсен һәр көн саен, һәр сәгать саен үзебез үк сизеп-тоеп торган һөнәрләрнең берсе. Сез төп дәүләт программаларын тормышка ашыруда, кешеләрне торак белән тәэмин итүдә, иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерүдән алып экология өлкәсендәге проектларга кадәр барлык стратегик бурычларны хәл кылуда катнашасыз.

Татарстанның төзелеш комплексы – йөзләрчә төзелеш компаниясе, дистәләрчә проект оешмасы һәм төзелеш материалларын җитештерүче предприятие ул. Бүген безнең тармак бик нык үсештә: инновацион материаллар кулланыла, алдынгы технологияләр гамәлгә кертелә, төзелеш өлкәсе актив төстә цифрлаша. Шул ук вакытта сез үз эшегездә нәкъ менә ветераннарның тәҗрибәсе һәм белеменә таянасыз. Бүген аларга аерым рәхмәт сүзләре җиткерәсе килә. Нәкъ менә алар республика сәнәгатенең иң зур предприятиеләрен төзегән, бүгенге инфраструктураны үстерүгә нык нигез салган.

Социаль һәм мәдәни объектларны төзеп, республикада яшәүчеләргә уңайлы мохит тудыруга бәйләп бетергесез өлеш кертүче бүгенге төзүчеләребезгә зур рәхмәт!

Кадерле дуслар! Республика төзүчеләренең югары биеклекне саклап, икътисад һәм социаль өлкәдә терәк булып калачакларына ышанам. Сезгә нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек, мактаулы хезмәтегездә яңа уңышлар телим!»

АЧЫ БАЛ

Татарстанның 8 районында күпләп бал кортлары үлгән. Шул рәвешле Теләче, Спас, Лаеш, Питрәч, Зәй, Бөгелмә, Чирмешән һәм Чистай районнарындагы умарталыкларга зур зыян салынган. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматларына караганда, әлеге җирлектәге үсемлекләрдән пробалар алынган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшерен-батырын түгел: бу хәл ел саен күзәтелеп тора. Узган ел да Татарстанның берничә районында күпләп бал кортлары үлгән иде. Биектау районының Ташлы Кавал авылында яшәүче Хәйбуллиннар хуҗалыгында гына да 10 миллион чамасы корт үлгәнлеге билгеле булды. Узган ел Арча районының Шекә авылында Нурулла Закировның умарталыгында да кортларның яртысы үлеп беткән иде. Бәхеткә, быел алар зыян күрүчеләр исемлегендә юк.

Ә менә Теләче районының Әбде авылындагы 8 хуҗалык быел бер көн эчендә 265 оя бал кортын югалтты. Алдагы көндә генә янәшәдәге рапс басуын агулаган булганнар. Умартачылар кортлар күпләп кырылуның төп сәбәбен шуннан күрә.

Әбде авылында яшәүче умартачы Александр Семенов 17 оя умарта асрый. «Бал кортлары ул көнне үзен бик сәер тотты. Башта исерек кебек арлы-бирле йөрделәр дә соңрак үлеп ятканнары да күренә башлады. Берзаман бөтен җир үлгән кортлар белән тулды», – ди ул.

Күршесендә яшәүче тагын бер умартачы Рәшит Гыйльметдинов та ул көнне үлгән бал кортларын чиләкләп җыйган. Кырларны агулаулары турында умартачыларны бер көн алдан гына кисәткәннәр. Закон буенча иса бу өч көн алдан эшләнергә тиеш.

«Татарстан умартачылары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Шәүкәт Хәйруллин да бу фаҗига кырларны агулы матдәләр белән эшкәртү аркасында килеп чыккан дип саный.

– Кырларны эшкәрткәндә кулланылган инсектицидлар дүрт класска бүленә. Беренче икесен сипкән очракта бал кортлары шундук үлә. Өченче, дүртенче классагылары да кортларга зыян сала. Әмма алар аннан үлми. Бал кортлары әнә шул беренчеләрен сибү аркасында кырылган булырга мөмкин, – дип фаразлый белгеч.

Лаеш районының Кече Елга авылында яшәүче танылган умартачы Зариповлар хуҗалыгындагы бал кортларына зыян килмәгән. Бүген алар барлыгы 350 оя бал корты үрчетә. Кызлары Нурия Зарипова сүзләренә караганда, быелгы һава торышы килешкән – баллары куе, сыйфатлы икән. Озак яумый торган яңгырлардан соң бал кортлары икенче кат табышка чыккан.

– Безнең умарталыкка зыян килмәде, Аллаһка шөкер. Фермерлар белән килешеп эшлибез. Кортларыбыз исәнсау булуның төп сәбәбе шунда. Алар кырларны бал кортлары нектар җыймый торган сәгатьләрдә генә эшкәртә, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Министрлык бар җирдә шундый тәртип кертү яклы. Быел хәтта агрономнар өчен бу уңайдан махсус укулар да оештырганнар. Шул рәвешле 130 белгеч бөҗәкләр серкәләндерә торган үсемлекләрне эшкәрткәндә куркынычсыз технологияләр куллану серләренә төшенгән.

– Укытуның нәтиҗәсе булды. 40 мең гектар чамасы җирдә үскән культуралар зарарсыз препаратлар ярдәмендә эшкәртелде. Бу бик нәтиҗәле ысул булып чыкты, – диелә министрлык хәбәрендә.

Әлеге алым Арча, Актаныш, Питрәч, Апас районнарында аеруча еш кулланылган. Министрлыкта әлеге тәҗрибәне республиканың башка районнарына да кертергә җыеналар. Бу, үз чиратында, бал кортлары күпләп кырылуга бәйле аяныч очракларны да киметер дип өметләнәләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАНДА УРЫП-ҖЫЮ

Республика кырларыннан 1 миллион 977,2 мең тонна уңыш җыеп алынган. Бу – 10 августка булган мәгълүмат. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, бер гектардан уртача 27,4 центнер уңыш чыга. Урып-җыю эшләре барлык мәйданның 48 процентында башкарылган.

ИҢ КҮП УҢЫШ ҖЫЙГАН 7 РАЙОН

	район	Җыелган уңыш, мең тонна	Уңдырышлылык ц/га
1	Тәтеш	108,4	42,4
2	Буа	94,7	30,3
3	Спас	82,2	33,2
4	Зәй	74,9	29,3
5	Әлки	73,9	28,9
6	Нурлат	72,1	30,1
7	Алексеевск	65,0	29,0
Республика буенча		**1977,2**	**27,4**

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте коллективына, «ТАТМЕДИА» акционер җәмгыяте филиалы «Чаян» журналы редакциясе» коллективына, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 3 номерлы камераль контроль бүлеге башлыгы **Арикова** Гүзәл Рәшид кызына, «Казанның психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат-йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры **Вәлитов** Морат Равил улына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы «Кояшкай» мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе укытучысы-дефектологы **Салиманова** Гүзәл Павловнага, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасы әйдәүче белгече **Гарипова** Гөлназ Габделгани кызына, «СОЛЛЕРС Алабуга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: җитештерү дирекциясенең буяу цехы маляры (тышкы линиядә) **Зарипов** Ирек Назыйм улына, баш бухгалтер урынбасары **Хәмидуллина** Рәйхан Исмәгыйль кызына, мәгълүмат технологияләре дирекциясенең ИТ-системалар һәм инфраструктурага хезмәт күрсәтү департаменты челтәр инфраструктурасын үстерү һәм аңа хезмәт күрсәтү бүлеге башлыгы **Шәйхетдинов** Марсель Рәшид улына, «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Михайлов** Юрий Валтеровичка **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Арзан хакка

Без соңгы елларда зарланырга күнегеп киттек. Сәбәбе дә бар: әйберләр кыйммәтләнә, ә хезмәт хакы артмый. Аның каравы һәртөрле ташламалар, акцияләр, дисконтлар һәм товар бәяләрен төшерә торган тагын әллә нинди әйбәт чаралар мыжгып тора.

Әйтик, бер ыштан алырга телисең икән, ул бер мең сум тора. Ә өчне алсаң, берсен бушка бирәләр. «Бушка бирү» дигән сүз ул кешегә тылсымлы бер дога кебек тәэсир итә, бөтен чирләреннән дәвалый, дөньясын нурга төрә. Вәт менә син дә кибеткә бер мең сумга бер чалбар алырга дип кергән җиреңнән ике меңгә өч чалбар алып чыгып китәсең. Бәхетле булып!!! Чөнки син беркая барып берни эшләмәгән җиреңнән бер мең сум акчаңны янга калдырдың. Ә янга калган акча ул эшләп тапканыннан берничек тә аерылмый. Без бит капитализмда яшибез: бүген синең кешелек дәрәҗәңне кылган игелегең дә, китергән файдаң да, күңел байлыгың да, хәтта мәхәббәт тә түгел, ә акча билгели. Акчаның кесәңә кергән яки чыкмыйча калган һәр берәмлеге ул – синең абруеңны, көчеңне, гайрәтеңне күрсәтүче тылсым. Ә дәрәҗәңне арттырырга мөмкинлек – һәр адымда.

Супермаркетта торасың менә. Шампунь, әйтик. Исе шундый тәмле, төсе йотып җибәрерлек, матур итеп төрелгән. Бары тик табигый әйберләрдән ясалган. Файдалы – дару урынына кулланылырлык. Үз хакы бер мең. Һәм 70% ташлама белән. Димәк, син бер дә юктан гына җиде йөз сумга хуҗа буласың. Капиталистик үлчәмдәге бәяң җиде йөз сумга күтәрелә. Баш тартырлык түгел бит. Хатыныңа булса да бүләк итәрсең. Ташламасын әйтеп тормый гына. Ә арырак – тагын арзан хакка...

Шул рәвешле ташламалы яки арзанрак әйберләр табу осталыгы камилләшә бара. Офыклар киңәя: кием-салымга, савыт-сабага, эш коралларына, электроникага, техникага... Бөтен нәрсәне дә ташлама белән, яки күпкә арзанрак бәягә алырга гадәтләнәсең. Сөенәсең шуңа. Чөнки синең кибеткә һәр сәяхәтең зур табыш белән тәмамлана, кайчагында кредит картаңны бушатып, бер айлык хезмәт хакыңа тиң ташлама аласың, шул күләмдә экономия ясыйсың. Акчаң янга кала. Дәрәҗәң күтәрелә.

Кайчагында тауарларның тумыштан гарип туганы да очрый: ике киюдә аяк киемеңнең үкчәсе төшә, күлмәгеңнең төймәсе кырыла, чалбарыңның төбе китә. Тик болар гына күңелеңне төшерә алмый. Беренчедән, андый очраклар сирәк. Икенчедән... Соң, җитмеш процент ташлама белән алынган әйбер бит ул. Кайберләре бөтенләй юк кына бәя тора. Ташламадан кергән капитал белән чагыштырганда, андый хилафлыкларның тузан бөртеге кадәр дә зыяны тими.

Кайвакытта ташламалар белән өч йөзгә алган мең сумлык әйберләреңне вак-төяк кибетләрдә дә очратасың. Монда алар йөз генә сум тора. Әй, ә... шулкадәр затлы нәрсә йөз сум тора аламыни инде! «Подделка» гынадыр. Шулай, әлбәттә.

Арзан хакка әйбер сатып алу хәзер сәнгать дәрәҗәсенә җитә. Урамга чыккан саен кибеткә керәсең, кибеткә кергән саен нәрсәдер аласың. Алып кайтасың да йортыңның берәр почмагына куясың. Фатирың – әйбер белән, күңелең шатлык белән тула. Кайчагында шуларга карап, сәгатьләр буена сокланып утырасың. Үзеңнең булдыклылыгыңа гына шулай озак сокланып була. Әнә теге капта торган тәлинкәләрне 80% ташлама белән алган идең, менә бу каптагы люстраларны ярты бәясенә, ә менә бу каптагы... Тукта, нәрсә соң әле монысында? И, ни булса да, арзанга алынган инде...

Шатлыкка уралып шулай беркадәр иркәләнгәч, компьютерыңны ачып, белдерүләр карый башлыйсың. Арзанрак хакка фатир табып булмас микән, дисең. Юкса өең көннән-көн бәләкәйләнә бара. Каплар арасында йөрү авырлаша...

Әйтеп кенә бактым

Бераз ятып торыш әле

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бу арада тел турында язарга тел кычытып тора әле. Сәбәпләре дә чыгып тора бит. Җитмәсә, халык шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев үсендереп тора. Без аның белән кайчак күрешмичәрәк торсак, телефон аша хәбәрләшеп, язышып торабыз. Берсендә: «Сездә нинди хәлләр бар?» – дип язган идем: «Йөреп кайтам да бераз ятып торыш әле», – дигән. Аннан соң: «Татар теле – могҗизалы тел бит ул, үзе ята, үзе тора», – дип тә өстәгән. Мин дә озак уйлап тормадым: «Могҗизалы гына түгел, дөнья йөзләрендә иң бай тел дип торабыз әле», – дидем.

Менә бу язганнарымда «тора» дигән сүз җөмлә саен диярлек. Бер яктан, бу телебезнең фәкыйрьлеген күрсәтеп тора кебек. Әмма икенче яктан, сөйләмгә күпме мәгънә төсмерләре биреп тора шушы бер сүз! Мондый хәл тагын кайсы халыкта бар? Күпмәгънәле сүзләр телебездә бихисап. Безнең белән бер генә халык та ярыша алмыйдыр. Мәсәлән, «көй» дигән сүзне генә алыйк. Әлеге дә баягы Разил дус та еш кына «бер көйгә яшәп ятам» яки «бер көе әле…» дип яза. Мин, үсенеп китеп, үземнән тагын өсти башлыйм: көйгә килү, көе киту, көйсез тормыш, көйсез хатын, көйсез ир, кеше көен көйләү… Теләсә, укучым үзе дә дәвам итсен!

Мине кайбер ата-аналарның: «Татар теле белән кая барасың?» – дигән сүзләре гаҗәпләндерә. Ходай телне каядыр бару өчен генә биргән микәнни? Дөрес, урысларда «Язык до Киева доведет» дигән сүз бар. Мин бу гыйбарәнең ничек килеп чыгуы белән кызыксынган идем. Фаразлар төрле, кеше ышанмаслыклары да бар, берсе, гомумән, бик сәер. Мәсәлән, әле 999 елда ук Никита Щекомяка атлы Киев кешесе, далада адашып йөргәндә, кыпчакларга юлыккан, ди. Тегеләр: «Нинди бәндә син, Никита?» – дип сораганнар. Никита үзенең Киевтан булуын, далада адашуын, ә Киевнның гаҗәп матур, бай шәһәр булуын кызыктыргыч итеп сөйләп биргән, ди. Шуннан кыпчак ханы Нунчак Никитаның телен бау белән үзенең аты койрыгына бәйләп куйган да, болар шул килеш Киевка барып җиткәннәр, имеш. Телнең Киевка илтүен үзенчә аңлату инде бу, кызык өчен чыгарылган бер уйдырма.

Ә менә кайбер риваятьләр шактый ук дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә кебек. Мәсәлән, элек Киев Русе христианнар өчен үзенә күрә бер мәккә саналган. Ул заманда поездлар, машиналар, күрсәткеч такталар, навигаторлар булмаган бит инде. Шуңа күрә Киевка очраган бер кешедән юлны сораштыра-сораштыра барганнар. Әле риваятьнең «күп сөйләшсәң, кыен ашарсың, ягъни таяк эләгер» дигән мәгънәдәгесе дә бар. Бу «Киев» сүзенең «кий», ягъни «таяк» дигән сүздән ясалганлыгы турындагы фаразга бәйле.

Кем әйтмешли, буласы булган инде, телнең Киевка илтүе турында гыйбарә исә, төрләнә-төрләнә, бүгенгә хәтле килеп җиткән, һәм аны менә без дә искә төшердек. Әмма сүзебез телнең адашканнарга юл күрсәтү өчен кулланылуына яки, күп сөйләшсәң, «таяк ашарсың» дигән мәгънәдә кулланылуына һич тә бәйле түгел. Миңа риваятьнең инглизчә варианты ошады. Ул «акыллы тел кая кирәк – шунда илтә» дигән мәгънәдә. Тел ул җәнлек-җанварларда да бар. Ә кеше өчен тел – фикерләү, яшәү рәвеше, ул – акыл, иман. Дустым Разил Вәлиевкә бу турыда да сүз каткан идем. Ул: «Дөньяның күпме илләрендә булдым, миннән: «Рус телен беләсеңме?» – дип берәү дә сорамады. Дөньяда кешене нинди тел белүе өчен түгел, ә акылы ни дәрәҗәдә булуына карап бәялиләр», – диде.

Ә безнең кайбер ата-аналар һаман да: «Татар теле белән кая барасың?» – дип бәхәсләшәләр. Балаларын русча укытып, зур кеше итәселәре килә. Шул ук вакытта ана телебез фәкыйрьләнә, аны куллану даирәсе тарая бара. «Тел» дигән олы байлыкны әрәмшәрәм итәбез. «Обидно, кәнишне, ой, как обидно!» Менә шулай дип зарланып ятыш инде.

ҖИДДӘ ОЧРАШУЫ БОРЫЛЫШ МИЗГЕЛЕ БУЛДЫМЫ?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Әле яңарак кына, 5–6 августта кырыктан артык илнең, Согуд Гарәбстанында очрашып, Россия – Украина конфликтын хәл итәргә омтылышы дөнья җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә булды. Саммитта Украинаның «тынычлык килешүе» каралу, Россия вәкилләренең анда чакырылмавы Мәскәүгә каршы зур уен уйнала дигән тәэсир калдыра иде. Күмәк аңгәмәнең беренче көнендә үк «Конфликтка кергән якларның сөйләшүләренең нигезенә илләрнең территориаль бөтенлеген һәм БМО уставын тану принцибы салынырга тиеш» дигән күмәк белдерү дә Россия файдасына түгел кебек күренде.

Әмма «территориаль бөтенлек» төшенчәсен бүгенге дөньяда бик төрле аңлыйлар. Әйтик, Мәскәү, мәсәлән, үзенең БМО уставы нигезендә хәрәкәт итүен гел ассызыклый һәм Украинаның бөтенлеге өчен җан атучы дәүләт позициясенә баса. Кремль аңлавында Кырым һәм 2022 елның 24 февраленнән соң яулап алынган барлык өлкәләр дә – Россия җирләре һәм рәхим итегез: яңа төбәкләргә кагылмыйча гына килешү төзегез дигән фикерне алга этәрә. Бу караштан Кремль ялгыз түгел. Бер үк җөмләне ике, хәтта берничә төрле аңлау һәм аңлату – бүгенге сәясәт өчен гадәти күренеш.

Әйдәгез, бер сорауга җавап бирик. Дәүләтләр, күмәк җыелып, кайда да булса барган сугыш хәрәкәтләрен туктата алалармы? Соңгы җитмеш елдан артык вакыт эчендә Фәләстыйн файдасына кабул ителгән БМО карарлары, төрле дәүләтләрнең белдерүләре язылган кәгазьләрне өйсәң, тау булыр иде, әмма бу Израильгә Газзәдә, Иерусалимда, Иордан елгасы ярлары буенда башбаштаклык итәргә аз гына да комачауламый. Соңгы утыз елда Карабах мәсьәләсе буенча Азәрбайҗанны яклап кабул ителгән карарлар да бихисап. Ләкин мәсьәлә Баку файдасына бары тик ике дәүләт – Төркия һәм Израиль белән тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә генә хәл ителә башлады. Ереван кемнәрнең генә аягына барып егылмасын, кемнәрдән генә ярдәм сорамасын, вазгыять Баку файдасына борылды һәм Пашинянга азәрбайҗаннар белән алар куйган шартта килешүдән башка конструктив юл калмады. Шуңа күрә аңлыйк: публикага игълан ителгән белдерүләр берни дә тормый, «Закон – что дышло: куда повернул, туда и вышло» дигән кагыйдә – хәзерге дөнья сәясәтендә төп кагыйдә ул. Шулай булгач, «Җиддә саммиты ник кирәк булды соң?» дигән сорау туа да куя бит инде.

Без саммит кысасында барган консультацияләрдә ниләр сөйләшүен белә алмыйбыз. Публикага ике юллык берни дә хәл итми торган документ кына игълан ителә. Андый документларны дистәләгән еллар буена кабул итеп торып була. Саммит исә глобаль кризис шартларында юрганнарны кай якка таба тартып, кем өстенә күпме ябарга дигән мәсьәләне хәл итү өчен кирәк. Россия – Украина конфликты үзенең төп функциясен үтәде инде: халыкара җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итеп торды. Хөкүмәтләр үз халыкларына ил эчендә кискенләшкән проблемаларны шул конфликт нәтиҗәсе итеп тәкъдим иттеләр. Барысына да Мәскәү гаепле (яисә Киев нацистлары аркасында хәл начарая) дигән тезислар искерә башлады. Россиянең көнбатышындагы конфликт стратегик тупикка килеп керде. Ике якның берсе дә алдыра алмый. Ә дөнья кризисы исә кискенләшә. Бәрелеш башланган көннәрдә Көнбатыш, рекордлы санкцияләр кертеп, Россияне тиз егарбыз дигән фикердә иде. Россия икътисады җимерелсә, башкаларга да сабак булачак, Вашингтонга каршы килүнең юньлегә илтмәячәген һәркем аңлаячак һәм Америка урнаштырган тәртипләр яңадан хөкем сөрә башлаячак – санкцияләрдән кителгән төп бонус шуннан гыйбарәт иде. Сер түгел: Мәскәүдә дә махсус хәрби операция озак бармас, соңыннан санкцияләр мәсьәләсе үзеннән-үзе хәл ителер дигән караштан тордылар, чөнки «җиңүчеләрне хөкем итмиләр». Ике якның да өметләре акланмады. Игътибар итегез: Мәскәүдә дә хәзер «барысы да план буенча бара» дигән сүзләр яңгырамый инде. Киресенчә, Кремль даими рәвештә сөйләшүләргә әзер икәнен белдерә, Киевны килешергә теләмәүдә гаепли, агрессор буларак тәкъдим итә.

«Ни өчен санкцияләр көтелгән нәтиҗәләрне бирмәде?» дигән сорауга җавап әзлик. Мәскәүгә каршы икътисад сугышында Көнбатыш ялгыз калды. Кытай, Һиндстан кебек державалар, Согуд Гарәбстаны кебек йогынтылы дәүләтләр, хәтта тышкы йогынтыга җиңел бирелүчән Урта Азия республикалары, чималга бай Африка дәүләтләре, Латин Америкасы илләре – берсе дә Вашингтон кубызына биергә чыкмады. Бәйсез позициягә басарга аларны объектив һәм субъектив сәбәпләр этәрде. Барлык сәбәпләрне дә санап чыгу мөмкин түгел. Күләмле монография язарга туры килер иде. Әйтик, Согуд принцы Мөхәммәд ибн Сәлмәнгә карата Байден ялгыш мөнәсәбәт күрсәтте. Аны үтерүче дип тамгалады һәм өстенә башка гаепләр өйде. Корольлек белән Америка мөнәсәбәтләрен тәмам бозып бетерде бу. Согудләр исә Россия тышавында төп божра булырга тиешләр иде. Алардан башка санкцияләр барабан кагудан бүтән берни дә түгел. Вашингтонның бернигә дә кирәкмәгән сәяси демаршлар нәтиҗәсендә Пекин белән мөнәсәбәтләрне тәмам җимереп бетерүе генә дә ни тора?! Тәкәбберлекләре шуңа этәрде. Нәтиҗәдә башында Кытай, Һиндстан, Согуд Гарәбстаны, Көньяк Африка Республикасы һәм Бразилия торган рәсми булмаган коалиция урнашты: үзара сәүдәдә доллардан баш тарта башладылар, Россия белән сәүдәне туктатасы урынга киңәйттеләр. Россия Көнбатышның технологик җиһазларын шулар аша ала башлады. Россиягә ярым аркадашлык итүче Төркия бар әле. Әрдоганга каршы пычрак уен корып, көнбатышлылар тагын тирән ялгышты. Хәзер алар моны аңлады инде. Кызу темплар белән Төркиягә якынаерга керештеләр. АКШ һәм Европа дипломатлары Кытайга ешлады. Америка Президентының милли куркынычсызлык буенча киңәшчесе Салливан Согуд принцының аягына барып егылды. Югарыда без санаган илләр һәм аларның иярченнәре «глобаль көньяк» дип исемләнделәр. Дөнья сәясәтендә глобаль көньякның алыштыргысыз роль уйнавы мәгълүм була башлады. Украина лидеры Зеленскийга Африка һәм Якын Көнчыгыш илләре белән актив эшләргә кушылды. Җиддә саммиты алдыннан ул да Согуд Гарәбстанында булды, сөйләшүләр үткәрде.

Игътибар итегез: Согуд корольлеге «глобаль көньяк»ның рәсми булмаган үзәге ролен үти башлады. Корольлектә Америка белән мөнәсәбәтләрне яхшыртырга каршы түгелләр, әмма җитди таләпләр куялар. Согудләргә каршы кем дә булса сугыш башласа, АКШ гарәпләр ягыннан сугышырга тиеш, чүлдә атом энергетикасын үстерү дә Вашингтон эше булсын, технологик сугыш кораллары сатуда Хиҗаз гарәпләренә чикләүләр булмасын. АКШ бу таләпләрнең барысын да үтәүне үз өстенә алып бетерә алмый. Әйтик, атом энергетикасына Израиль каршы. Фәләстыйнга бәйле мәсьәләләр дә бар әле анда. Гарәпләр Израильнең Фәләстыйн җирләрен үзләштерүдән туктавын таләп итә. Израиль исә ул таләпкә буйсынмый, әмма гарәп икътисадына инвестицияләр ясарга әзер. Мөнәсәбәтләрнең бик катлаулы йомгагы төенләнә.

Җиддә саммиты шул катлаулы төеннәрне чишү юлларын эзләү өчен оештырыла. Аның гарәп туфрагында булуы зур әһәмияткә ия. Андый очрашу Копенгагенда бер булган иде инде. Кытай катнашмады. Гарәпләр чиннарны саммитка тартып китерлек бердәнбер көч буларак карала башлады. Чынлап та, башта каршы торса да, Си үз вәкилен Җиддәгә озатты. Читтә калып булмый да иде, чөнки Кытай экспорты айдан-айга түбәнәя. Россиягә товар сатуны күпме генә арттырмасын, Мәскәү белән сәүдә әйләнеше барыбер Көнбатыш белән товар алышу янында бик кечкенә булып кала. Соңгы көннәрдә Кытай кризисы исә кискенләшә. Җиддә очрашуы Украинаны кайгыртып түгел, глобаль кризис агышында «глобаль көньяк» белән Көнбатыш мөнәсәбәтләрен җайга салу өчен кирәк иде. Әгәр шулар җайга салынса, Россия үзеннән-үзе юл кырыена төшеп кала. Украина проблемасы да шуның белән хәл ителә диярлек, ягъни, русча әйтсәк, «побочный эффект» бирә. Һәрхәлдә, яклар шулай уйлый. Әлегә көтелгән нәтиҗәләр юк. Саммитның яңа раунды көтелә. Анысына да Мәскәүне беркем дә чакырырга җыенмый. Гарәпләр һәм төрекләр Көнбатыш белән бер сафка басса, Россия өчен бик кыен булачак. Көнбатыш шуңа омтыла да инде. Әнкараның дөньяда барган процессларда тоткан урыны бик кызыклы. Нигер фетнәчеләре митингларга башта Россия флаглары күтәреп чыкканнар иде. Соңгы көннәрдә Төркия флаглары күренә. Әллә нинди без аңламаган агымнар бар «дөнья сәясәте» дигән океан астында.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

СУСАУ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кайбер авылларда сусызлыктан интеккәч, коелар казырга мәҗбүр булалар.

Баш бәласе

Яшел Үзән районының Рус Әҗәле авылы халкы әйтүенчә, аларда су – иң зур баш бәласе. Сунын сыйфаты гына түгел, аның белән тәэмин ителеш тә борчый аларны.

– Беренчедән, безнең авылда су эчәргә яраксыз. Икенчедән, бик начар ага. Шәхсән минем йортка су ел дәвамында бик начар килә. Мин бу авылга сигез ел элек кенә күченеп кайттым. Башта аны-моны уйламыйча, краннан аккан суны кайнатып эчә идем. Тик бервакыт әле тege, әле бу җирем авырта башлады. Кызым тикшерүгә алып баргач, бавырда ком барлыгын әйттеләр. Дәвалансам да, ике айдан ул ташка әйләнде, – диде Гүзәл Сәлахова.

Гадәттә, авылларда су белән тәэмин итүдә авырлыклар җаен булса, биредә яшәүчеләр әйтүенчә, аларда су кышын да бик әз ага.

– Бу хәлләргә өч ел тирәсе инде. Аңа кадәр барысы да тәртиптә иде. Барысын да җәйге корылыкка сылтап калдырырга булыр иде, тик мин иртә белән намазга торам. Инде ул вакытта да су булмый. Кышын да шул ук хәл. Безнең авылда беркем дә кер машинасыннан файдалана алмый, чөнки аны кабызудан мәгънә юк. Берара әйбәт кенә агып та ала ул, тик биш минуттан кинәт туктый. Су безгә генә түгел, биш терлегебезгә дә кирәк бит. Аларга коедан эчерәбез, – диде шушы авылда яшәүче Ландыш апа.

Авыл халкы чиста суны берничә чакрым ераклыктагы авылдан барып ала. Хуҗалыкка су начар килгәнлектән, кое казытучылар да күп.

– Минем коем да, су ташырга машинам да юк, – ди Гүзәл Сәлахова. – Шуңа күрә аны һәрвакыт кемгәдер әйтеп алып кайттырам. Аның өчен 500 сум түлим. Шулай итеп, краннан аккан су өчен торак-коммуналь хуҗалыкка да, барып алган кешегә дә акча чыгарып салырга туры килә.

Суның сыйфатына килгәндә, авыл халкы әйтүенчә, Роспотребнадзор белгечләре килеп, ике тапкыр анализ да алып киткәннәр. Соңгы нәтиҗәләр, мәсәлән, быел апрель аенда гына билгеле булган. Ул документларны без дә күрдек. Суның составында, чыннан да, тозлар һәм тимернең чамадан тыш күп булуы ачыкланган.

Баргач та, без авыл җирлеге башлыгы Гөлнара Семахинаны күреп сөйләшкән идек. Ул вакытта халыкны сөендерерлек бер сүз дә әйтмәгән иде. Язмаы әзерләгәндә, тагын бер тапкыр хәлләрен белешеп алдык.

– Авылны су белән тәэмин итү – «Нурлат» торак-коммуналь хуҗалыгы карамагында, – диде ул. – Сез килеп киткәннән соң, оешманың яңа җитәкчесе үзенең командасы белән килеп, торбаларны тутыктан чистарттырды. Проблемалар аннан соң да тулысынча бетмәгәч, торбаларны өрдерделәр. Шуннан соң хәлләр уңайланды. Су да кинәт туктап калмый башлады, өзлексез килә. Әлегә халыктан зар ишетелми. Без инде киләчәктә күпмедер аралыкта торбаларны алыштырмаслармы икән, дип өметләнәбез. Ләкин бу – безнең хыял гына. Берәр вакыт акча арттыра алсалар, нәзегрәк торбаны алыштыру мөмкинлеген караячаклар.

Су белән тәэмин ителеше җайлап куйсалар да, сыйфатына исә берничек тә тәэсир итә алмауларын әйтте Гөлнара Семахина.

– Иделнең бу як ярындагы авылларның барысында да суның сыйфаты шундый. Җир асты сулары якын булганлыктан, составы чыннан да начар. Ләкин без инде аныcын берни дә эшләтә алмыйбыз, – диде ул.

Сәбәпләре төрле

Суның басымы аз булу яки бер тамчы суга интегү – җаен авылларның үзәгенә үткән тема. Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының матбугат үзәге әйтүенчә, җәй көне «пик» сәгатьләрендә сүүткәргеч челтәрләрдән файдалану 5–6 тапкыр арта. Кайбер районнарда бу 20 процентка кадәр җитә.

– Гадәттә, ел саен бу вакытта халыктан мөрәҗәгатьләр күп кабул ителә. Су азлыкның яки бөтенләй килмәүнең беренче сәбәбе ихтыяҗ арту булса, икенчесе – халыкның урам, бистә челтәрләренә игътибарсызлыгы. Казанга якын урнашкан авыллар халкы ел әйләнәсе яши торган дача бистәләре булып санала. Аларда торак йортлар күп төзелә. Коттедж микрорайоннары барлыкка килә. Шул ук вакытта су челтәрләренең диаметры элеккечә кала, – ди министрлык белгечләре.

Алар белдерүенчә, су белән тәэмин итүче оешмалар вазгыятьне яхшырту максатыннан чаралар да күрәләр үзе. Артезиан скважиналарын карап тоталар, тузган сүүткәргечләрне алыштыралар, яңа җиһазлар сатып алалар, су басымын арттыру өчен төрле эшләр башкаралар, шулай ук су килүне туктатырга мөмкин булган җайланмаларның булу-булмавын тикшерәләр.

Проблема бер булса да, сәбәпләре һәм чишү юллары төрле. Кайдадыр башня җитми, кайдадыр яңа скважиналар бораулау, кайдадыр яңа су алу корылмасын ясау кирәк. Татарстанда искергән, черек торбалар да күп.

Су һәм авырулар

Кызганыч, су булу-булмау күзгә күренеп тора торган проблема булса, аның сыйфаты – күзгә күренмәс (тәме һәм төсе суга чыкмаган очракта, билгеле), ләкин сәламәтлеккә тирән эз сала торган җитди мәсьәлә.

Моннан 10 ел элек Мәскәү галимнәре – Россия Фәннәр академиясенең Су проблемалары институты су саклау лабораториясенең әйдәп баручы белгече Наталья Митина һәм аспирант Динара Идковская Татарстан сулыкларын тикшерә. Алар фикеренчә, кешенең саулыгы, экология куркынычсызлыгы табигый сулыкларның һәм эчә торган суның сыйфатына турыдан-туры бәйле. «Татарстанның күпчелек районнарындагы суларда нитрат, азот, фенол, бакыр, хром, марганец чамадан тыш күп, – дигән нәтиҗәгә килгән белгечләр. – Һәм бу сәнәгать һәм авыл хуҗалыгында кулланыла торган суларга гына түгел, ә шәһәр һәм авыл халкы эчә торган суга да кагыла. Әйтик, бу матдәләр халык арасында популяр булган чишмәләрдә дә очрый».

Алар төзегән махсус картадан аңлашылганча, авыруларның таралуы халыкны эчәр су белән тәэмин итәр өчен актив рәвештә кулланылган җир асты суларының өскә чыгуы белән туры килә. Бу, үз чиратында, җир асты суларының санитар-гигиена нормаларына туры килмәвен күрсәтә. Тикшерүчеләр фикеренчә, халык күпләп яшәгән җирлекләрдә авырулар да тизрәк тарала. Ләкин шулай да искәрмәләр бар. Әйтик, бу исемлеккә алар Чүпрәле, Ютазы һәм төньяк районнарны кертмәгән.

Тик халкы күп булган сәнәгать районнарында вазгыять башкача. Әйтик, нефть сәнәгате башкаласы Әлмәт һәм аннан көньяк-көнчыгышка табарак урнашкан бистә һәм шәһәрләрне атый алар. Әлегә исемлеккә шулай ук машина төзелеше һәм нефть химиясе буенча махсуслашкан Казан – Яшел Үзән сәнәгать узеле да, Түбән Кама, Тукай, Зәй, Алабуга районнары да кергән.

Актаныш, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск районнары авылларында яшәүчеләрдән дә суның сыйфатына кагылышлы зарларны еш ишетергә туры килде. Әйтик, күптән түгел генә Актаныш районына эш сәфәренә баргач, Татар Суыксуы авылында яшәүче Елена Ирдуганова авыл суыннан канәгатьсезлек белдерде.

– Скважинаны 50–150 метрга кадәр казырга тиешләр иде. Тик аны 20–25 метр гына бораулыйдылар, нәтиҗәдә без хәзер грунт суларын эчәргә мәҗбүр, – диде ул. – Ә анда кальций күп. 3 ел элек ясаткан анализлар да су составында кальций һәм аммиакның күп булуын ачыклады. Кальций кирәгеннән артык күп булган очракта, калкансыман биз авырулары килеп чыгу бар, дип әйтәләр. Бу сүзләргә ышанмый мөмкин түгел, чөнки безнең авылда бу авырулар белән чирләүчеләр бик күп. Безнең районда нефть чыгарыла торган Аеш, Кәзкәй, Суыксу авылларында, гомумән, суның сыйфаты һәрвакыт начар булды. Биредә рак белән авыручылар да күп.

Наталья Митина сүзләренчә, суда хром һәм фенол күп булган очракта, зурлар һәм балалар арасында яман шеш, кан һәм кан әйләнешенә бәйле авырулар, тән тиресе, эндокрин система, ашкайнату әгъзалары, сөяк-мускул системасы авырулары, психик тайпылышлар күпләп очрарга мөмкин.

– Авылларда яшәүче күпчелек балаларның авырулары авыл хуҗалыгы кулланылышында булган сулыкларга бәйле, – ди Наталья Митина. – Алар буа, елга, күлләрдә озаклап һәм еш коена. Әлеге сулыкларга кырлардан һәм фермалардан сульфат, хлорид, фосфор, аммоний азоты, нитратлар, нитритлар эләгә. Шуңа күрә мондый сулыкларда еш коенган балаларда эндокрин системасы һәм кан әйләнеше әгъзалары авырулары ешрак күзәтелә.

Дөрес, экологик яктан чиста районнар да бар. Аларда сулыкларны сәнәгать оешмалары ул дәрәҗәдә пычратмый. Шунлыктан авыручылар да азрак. Болар – Балтач, Кукмара, Саба, Арча, Әлки, Алексеевск, Нурлат, Спас, Чүпрәле һәм Буа районнары.

Геолог, «Право на чистую воду» иҗтимагый комитеты координаторы Николай Петров әйтүенчә, әлеге тикшеренүләр моннан ун ел элек уздырылса да, актуальлеген югалтмый.

– Бүген дә вазгыятьнең шул бер дәрәҗәдә торуына, әле алай гына да түгел, тагын да начарланып китүенә бер дә шикләнмим, – ди ул. – Мин Экология министрлыгында әйдәп баручы белгеч булып эшләгәндә дә, бу турыда гел әйтә килдем. 2013 елда Мәскәү галимнәре зур эш башкарган. Мондый тикшерүләр күпкә ешрак булырга тиеш. Тик, кызганыч, алар бик сирәк оештырыла.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

САНАГАННЫ ЯРАТА

Менә син әле генә, уч тутырып, хезмәт хакы алдың, берникадәр вакыт «патшаларча» яшәдең, ә аннары... Аннары кесәң тирәнлеген үлчәргә генә кала. Чөнки, көндәлек чыгымнар өермәсендә бөтерелеп, акчаның кая киткәнен сизми дә, аңламый да каласың. Баксаң, эшләп тапкан акчаның яртысын диярлек «ашый» торган гадәтләр бар икән. «ВТ» шуларны ачыклап, акчаны юк-барга сарыф итмәү һәм маяны арттыру ысулларын барлады.

ru.freepik

Кулда булганда кадерлә

Практик инвестицияләү мәктәбе җитәкчесе, финанс консультанты, практик инвестор Федор Сидоров фикеренчә, гадәтләнгән тормыш рәвешеннән баш тартмыйча гына да, чыгымнарны киметүгә ирешеп була. Моның өчен киңәшләре дә бар.

– Акча санаганны ярата, димәк, керем-чыгымнарны язып барырга кирәк. Бик гади киңәш инде бу. Гадәттә, кешеләрнең болай эшләмәскә ике сәбәбе була: акчаны санап тотарга ихтыяҗ юк, чөнки ул аз, йә санап булмаслык күп. Еш кына без көндәлектә башкара торган вактөяк сатып алуларны чыгым рәтенә кертмибез. Әмма тамчыдан күл җыела. Акча күп, шуңа санап тотмыйм дигәннән, финанс белемнәрең сай булса, акчаның күплеге генә коткармый, – ди белгеч.

Керем һәм чыгымнарны язып баруны күңелле итәргә дә мөмкин. Әйтик, гадәти кәгазьгә язып барганчы, Exel таблицасына тутырырга, мобиль кушымталар кулланырга.

– Хисап алып бару – бер нәрсә, аны даими башкару да мөһим. Баш мие яңалыкны, үзгәрешләрне авыр кабул итә инде ул. Шуңа күрә башлангыч этапта сабырлык та, кызыксыну да күп кирәк булыр. Психологлар әйтүенчә, гадәт 21–40 көн эчендә формалаша. Акчагызның нәрсәгә тотылганын белмичә баеп булмаячак, – ди белгеч. – Керем-чыгым хисабын алып баргач, нәрсә өчен акчаны күбрәк сарыф итүегез ачык күренәчәк. Минем тәҗрибәмдә шундый хәлләрнең дә булганы бар: хәмер, тәмәке белән дус булган кешеләр, бу гадәтләргә никадәр акча тотуларын күргәч, эчүне дә, тартуны да ташлады. Иң мөһиме – үз-үзеңне чикләү түгел, ә акчага һәм ул тотыла торган тармакларга аек акыл белән карау. «Экономия» дигән сүзне башыгызда тотмагыз. Ул, гадәттә, тискәре мәгънәдә кулланыла. «Киләчәккә инвестиция» дигән заманча сүз кулլансагыз, баш мие бөтенләй башкача эшли башлаячак.

Федор Сидоров «чикләү», «акчаны янга калдыру» кебек сүзләр урынына менә мондыйларын кабатларга тәкъдим итә:

- ✓*«Мин акчаны саклыйм»;*
- ✓*«Мин тотып калган акчаны үсеш һәм инвестиция өчен кулланам»;*
- ✓*«Мин тормышымны һәм матди мөмкинлекләремне контрольдә тотам».*

Федор Сидоров әйтүенчә, чыгымнарны киметү дигәндә һәр кешегә туры килерлек формула юк. Чөнки һәркем төрле тормыш кичерә, төрлечә яши.

– Чыгымнарны киметү буенча һәркемгә утырып уйларга, анализ ясарга киңәш итәм. Мин мисаллар гына китерәм. Әйтик, кофейняларда эчемлек сатып алганчы (гадәттә, 150–300 сум була ул), аны өйдә ясагыз. Өйгә азык-төлек китертү белән мавыкмагыз. Китереп бирү бәясе кыйммәт. Кибетләрдә акция, кэшбек, ташламалар булып тора, даими күзәтеп барыгыз. Карталгыздагы «автоплатеж» хезмәтен тикшерегез. Бәлки, сезгә кирәкмәгән хезмәтләр кушылгандыр. Шушы ук киңәш элемтә тарифына да кагыла.

Шәхси финанслар буенча белгеч Максим Темченко әйтүенчә, хезмәт хакыннан хезмәт хакына кадәр яшәгән кеше дә маяга дип берникадәр сумма җыя башларга тиеш. «Әлбәттә, бу җиңел түгел. Күпләр бөтен керем-чыгымнардан калган сумманы маяга дип туплый. Ягъни ай азагында калган сумманы. Тик мин башкача эшләргә киңәш итәр идем. Кулга керем алуга, шул сумманың бер өлешен алып куярга. Башта сез үзегезгә түләргә тиеш. Аннан соң гына коммуналь хезмәтләргә, кредитка, азык-төлеккә. Җыйган акчагыз – сезнең киләчәгегез ул, матди яктан бәйсезлегегез күрсәткече. Күпләр керемнең 10 процентын алып калырга куша. Аздан башларга тәкъдим итәм. Мәсәлән, 3 проценттан. Аена 500 сум алып кала алсагыз да, елына 6000 сум дигән сүз бит бу. «Инвестицион портфель» ачарга, кертем итеп банкка салырга мөмкин», – ди белгеч.

Начар гадәтләр

1 **ТӘМӘКЕ ТАРТУ**. Бу гадәт акча янчыгына гына түгел, сәламәтлеккә дә зыян сала. Акчагызның төтенгә әйләнмәвен теләсәгез, тәмәке тартудан баш тартырга кирәк. Бәлки, математик исәпләүләр моңа этәргеч булыр. Әйтик, кеше көненә 200 сумлык бер пачка тәмәке тартып бетерә, ди. 200 сумны елның 365 көненә тапкырласак, аз да түгел, күп тә түгел – 73000 мең сум килеп чыга.

2 **ФАСТФУД һӘМ ГАЗЛЫ ЭЧЕМЛЕКЛӘР.** Болары да матди һәм рухи яктан зыянлы гадәтләр рәтенә керә. Әйе, фастфуд – кызыктыргыч ризык. Әмма ул өй ризыгыннан күпкә кыйммәтрәк. Чагыштыру өчен, гадәти ашханә менюсына һәм фастфуд нокталары тәкъдим итә торган ризыкларның бәяләренә күз салу да җитә. Баллы сулар белән дә шул ук хәл. Аларны даими эчеп торган кеше көненә 150–200 сумлап акчасын сарыф итә дигән сүз.

3 **ТАКСИ.** Сүз дә юк, бу хезмәттән бөтенләй баш тартып булмый. Әмма яшерен-батырын түгел, күп очракта таксины ялкаулык өстен чыкканга күрә чакырабыз бит. Яисә вакытны дөрес итеп бүлә белмәгәнгә күрә. Әйтик, эшкә соңга калганда.

4 **ЭЛЕМТӘ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ.** Күпләр элемтәнең «безлимитный» дигән төренә кызыга. Әмма аны сайлаганчы, җиде кат уйлау зыян итмәс. Сез телефон аша көн саен, сәгатьләр буе аралашасызмы? Яисә көнгә ничәдер минут җитәме? Тарифны дөрес итеп сайлау аена 1 мең сумга кадәр акчаны янга калдырырга булышачак. Ел буена исәпләсәң, шактый сумма бу.

5 **БУРЫЧКА АКЧА БИРҮ.** Якын кешеләргә матди яктан булышу – яхшы гамәлдер. Әмма финанс белеме ягыннан бу бер дә хуплана торган эш түгел. Чөнки эшләп тапкан акчагызның барлык өлеше дә сезнең карамакта түгел дигән сүз (мәсәлән, 100 мең сум хезмәт хакының 80 меңе генә бар).

6 **УЙЛАМЫЙЧА НИДЕР САТЫП АЛУ.** Кибеткә исемлек төзеп барырга дип юкка гына әйтми белгечләр. Кешедә күзе төшкән нәрсәне сатып алу гадәте бар. Кибеткә һәрвакыт максатчан йөрергә кирәк. Акчаны да кирәк әйберләрне сатып алырга җитәрлек кенә итеп йөртергә. Иң яхшысы – кәгазь акча белән йөрергә. Чөнки карта белән түләгәндә күпме акча сарыф ителгәненә һәм картада күпме калганына әллә ни игътибар бирмисең. Билгеле бер вакыт җиткәнче, әлбәттә.

7 **САГЫЗ, КӨНБАГЫШ.** Фастфуд һәм газлы эчемлекләр очрагында кебек үк, сагыз чәйнәү, көнбагыш чиртү – начар гадәт. Әллә ни югалтмыйм, дисәгез дә, саный башласаң, түгәрәк суммалар җыелырга мөмкин. Әйтик, яхшы саналган сагызның да хәзер хакы 50–100 сумнан ким түгел. Аена дүрт тапкыр сагыз алган очракта гына да, 400 сум тирәсе акча сарыф ителә бит.

8 **ЯРЫМФАБРИКАТЛАР САТЫП АЛУ.** Иң беренче чиратта, алар кыйммәт. Аларны кеше үзе дә ясап, катырып куя ала. Ялкаулыкны җиңсә, әлбәттә.

9 **ТӨРЛЕ ИНТЕРНЕТ-ХЕЗМӘТЛӘР ӨЧЕН ТҮЛӘҮ.** Телефон, ноутбук, гомумән, гаджетларыбызны кызыклы итә торган интернет-хезмәтләр хәзерге заманда арзан түгел. Әле аларның кайсылары ай саен билгеле бер сумма сорый (әйтик, музыка тыңлау өчен).

Сан

Сез керем-чыгымнарыгызны тикшереп торасызмы? «Работа.ру» һәм «Сбер» хезмәтләре белгечләре ил халкыннан шул хакта сорашкан. Нәтиҗәләр болайрак:

62% >> чыгымнарны контрольдә тота	**12%** >> ай азагында чыгымнарын барлый
10% >> әллә ни контрольдә тотмый	**9%** >> контрольдә тотмый һәм җыенмый
6% >> исәп-хисап алып бару турында хыяллана	

Сораштырудан күренгәнчә, акча иң күп тотыла торган чыгымнар рәтенә торак-коммуналь хезмәтләр (26%), балалар өчен кирәк-яраклар сатып алу (24%), кредит түләүләре (20%), интернет һәм элемтә (19%), белем алу (17%), кием-салым (16%), машинаны карап тоту (13%) кергән.

18 август көнне сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә ГЫЙЛАҖИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Субсидия нигә юк?

Әниебез Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында яши. Аңа «Хезмәт ветераны» исеме өчен субсидия каралган. Әмма ул килүдән туктады. Гыйнвар аенда 3 сум 45 тиен күләмдәге бурычы барлыгы ачыкланды. Без бу бурычны түләдек. Әмма субсидия һаман да килми. Безгә нишләргә?

Алсу.
Әгерҗе районы Иж-Бубый авылы

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Рафаил Гыйниятуллин:
– Әниегезнең салым түләү буенча бурычлары булмау турында белешмә кабул ителгән, субсидия бирү яңартылган. Әлеге субсидия, яңадан исәпләнеп, 2023 елның сентябрендә күчереләчәк.

Тавышланучыларны нишләтергә?

Миңа – 73 яшь, Биектауда яшим. Төн буе урамда шаулашып чыгалар, машиналардан музыка акырталар. Оныклар куркып уяна. Кемгә мөрәҗәгать итеп карыйк икән?

Биектаудан Ринат бабагыз

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Иң элек әлеге проблемага кагылышлы законнарга күз салыйк. ГОСТ Р 52231-2004 стандарты автомобильләрдән чыга торган тавышны 96 децибелдан да артык булырга тиеш түгел дип билгели. Бу очракта двигатель тавышы гына түгел, ә машина салоныннан килә торган һәм сигнализация тавышы турында да сүз бара.

Хәзерге вакытта тавышның рөхсәт ителгән чиге санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм 1.2.3685-21 нормативлары белән дә көйләнә. Бу документ нигезендә, торак йортлар белән турыдан-туры тоташкан территориядә тавышның максималь дәрәҗәсе көндез 55 децибелдан, төнлә (23.00 сәгатьтән 07.00 сәгатькә кадәр) 45 децибелдан артык булмавы билгеләнә. Күрсәтмәләрне бозган өчен җаваплылык РФ Административ хокук бозулар Кодексының 6.4 маддәсендә билгеләнгән. Гади кешеләр өчен штраф күләме – 500–1000 сум.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Нәрсә эшләргә?

1. Үзара аңлашуга өметләнеп, шау-шулы машина хуҗасына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Ләкин бу очракта әйткәләшү, конфликт туу куркынычы бар.
2. Полиция чакыру. Полиция хезмәткәрләре бу очракта законсыз гамәлләрне туктатырга, административ хокук бозу турында беркетмә төзергә тиеш.

Пенсия ник түләнми?

Улым Казанда яши. 30 ел зыянлы җитештерү өлкәсендә эшләде. 16 елын – Россиядә, 14 елын – Үзбәкстанда. 50 яшь тулгач, пенсия белешен йөри башлады. Үзбәкстан белән килешү юк дип, пенсия түләмибез, диделәр. Бу очракта нишләргә?

Әтнәдән Хәйдәр бабагыз

Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская:
– Россия 1992 елның 13 мартында БДБ дәүләтләрендә яшәүчеләрнең пенсиягә хокукларын гарантияләү турында килешүне кабул итте. Әрмәнстан, Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Россия, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Украинада яшәүчеләрне пенсия белән тәэмин итүгә кагыла ул. Килешү СССР таркалганнан соң пенсиягә хокукны, шулай ук совет чорында тупланган хезмәт стажын саклап калу өчен кирәк булды.

Россия 2022 елда әлеге Килешүдән чыкты. Халыкара килешүнең гамәлдә булуын туктату хәзер СССР таркалганчы – 1991 елның 1 гыйнварына кадәр генә элекке совет республикаларында тупланган эш стажының исәпкә алынуын аңлата.

Молдавиядән, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан яки Украинадан Россиягә килеп, Россия гражданлыгын яки бирегә яшәүгә рөхсәт алучылар безнең ил законнары буенча пенсия ала. Россия законнары нигезендә, зарарлы производствода эшләүчеләр вакытыннан алда пенсиягә чыгарга мөмкин. Җир асты эшләрендә, кайнар цехларда, зарарлы производстволарда эшләүче хатын-кызлар – 45, ирләр 50 яшьтә пенсиягә чыга. Әмма билгеле бер шартлар үтәлергә: зарарлы производствода – 10 еллык эш стажына, шул ук вакытта 20 еллык гомуми эш стажына ия булу кирәк. Кызганычка, мөрәҗәгать итүченең, Россия дәүләтенең Килешүдән чыгуы сәбәпле, нәкъ менә иминият стажы тулып җитми. Шуңа күрә аңа пенсияне вакытыннан алда билгеләүдән баш тартканнар.

Бу карар буенча Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлегенә мөрәҗәгать итәргә яки аңа суд аша шикаять белдерергә мөмкин.

Әйтмичә генә булмыймы?

Кибеткә товар кайтарган вакытта, паспорттагы мәгълүматларны сорыйлар. Бу нәрсә өчен кирәк икән? Аны хәбәр итми генә булмыймы?

Раннур. Чаллы

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Бу очракта паспорт сатып алучының шәхесен раслау өчен, ягъни акча алучыны идентификацияләү өчен кирәк. Сатучылар үз эшчәнлекләрен башкарганда, РФ Гражданлык кодексы нигезләмәләренә генә түгел, ә махсус методик киңәшләр һәм күрсәтмәләргә дә таяна. Бу документлар буенча, акча сатып алучының шәхесен раслаганнан соң гына кире кайтарыла ала. Моннан тыш, шәхесне ачыклый торган мәгълүмат кибеттә сезнең исемнән ни дә булса сатып алмасыннар өчен дә кирәк.

Кире кайтара аламмы?

1996 елда пенсиягә чыктым. 2000 елга кадәр эшләдем. Эшләгәч, яртı пенсиямне алып калдылар. Ул акчаны кире кайтарып буламы?

Исемем редакция өчен генә

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте җитәкчесе Альбина Никандрова:
– 1991 елга кадәр (шул исәптән совет чорында) стажы булган гражданнарның пенсия хокукларын яңадан бәяләү, ягъни валоризация 2009 елда узды. Ул вакытта белгечләр тарафыннан татарстанлыларның пенсияләрен яңадан исәпләү буенча зур эш башкарылды. 2010 елга кадәр билгеләнгән барлык пенсияләр яңадан исәпләнде. 2010 елдан исә пенсияләр валоризацияне исәпкә алып билгеләнә. Димәк, гражданнарның совет чорындагы стажы инде исәпкә алынган, пенсияләрне яңадан исәпләүнең кирәге юк.

Эшләүче пенсионерларның пенсияләрен яңадан исәпләүгә килгәндә, алар иминият пенсиясе һәм фиксацияләнгән түләү (планлы индексацияләрне исәпкә алмыйча) алалар. Аларның пенсияләрен яңадан исәпләү һәр елның 1 августында, пенсионерларның узган елгы гомуми хезмәт хакын исәпкә алып үткәрелә. Пенсиягә өстәмә күләме һәркем өчен аерым исәпләнә (әмма закон буенча өч пенсия коэффициентыннан артмаска тиеш).

Бирелергә тиешме?

Күптән түгел эшемне алыштырдым. Алдагы эш урынымда алынмаган ялым (отпуск) калган булып чыкты. Аның өчен каралган матди ярдәм бирелергә тиешме?

Ләйсән. Казан

«ВТ» юристы Булат Закиров:
– Бу сорауга тәгаен җавап бирү өчен, хезмәт килешүе, коллектив килешүе яки матди ярдәм турындагы нигезләмәләр һ. б. документлар белән танышырга кирәк. РФ Хезмәт кодексының 140 нчы маддәсе нигезендә, хезмәт килешүе туктатылган очракта, эш бирүче бирергә тиешле барлык түләү акчалар хезмәткәр эштән азат ителгән көнне түләнә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Рәхмәт!

Июль аенда ирем Камил белән онкология хастаханәсенә юл тоттык. Табибка күренәсе көн иде. Маршрут автобусына утырып, ерак та китмәдек, иремнең хәле начарланды. Инде узармы дисәм, киресенчә, тагын да начарланды гына. Мин, ярдәм сорап, кычкыра ук башладым. Ирем аңын җуйды. Автобус йөртүче шундук туктады. Кондуктор белән ярдәмгә килделәр. Барлык пассажирларны төшерделәр. Тизрәк «ашыгыч ярдәм» чакыра башладылар. 30 минут табибларны көттек. Алар шул вакыт эчендә янибызда булдылар. Шул ир-атларга чиксез рәхмәтлебез. Шөкер, иремнең хәлләре ярыйсы. Кеше кайгысына битараф булмаганнары өчен, без утырган маршрут автобусында (ничәнче номерлы икәнен дә онытттым) эшләүче егетләргә мең рәхмәт! Аллаһы Тәгалә үзегезне бәла-казалардан саклап йөртсен.

Сәкинә ГЫЙМАЗОВА. Казан

Укучы сүзе

«САГЫНУ» (Роберт Миңнуллинга бәйле истәлекләр) ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Яраткан шагыйрем. Гади, ихлас, үтемле итеп язылган шигырьләре һәрбер кешенең күңел кылларын тибрәтерлек. Мәңгелек шагыйрь!

Нурия ШӘРИФУЛЛИНА

***

Исән чагында шигырьләрен бик яратып укый идем. Аның сөйләшүен, тавышын бик ярата идем, телевизордан күрсәм, йотлыгып тыңладым. Хәзер инде гел сагынып искә алам.

Әминә ДӘМИНОВА

«ГОМЕР ЗАЯГА УЗМАСЫН» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Бик тә хөрмәт итәм сезне, тигезлектә, бәхеткә төренеп яшәргә язсын, саулыктан аермасын. Сездән карап, тормыш көтәргә, барына да өлгерергә, ике яктан да әти-әниләрне хөрмәт итеп, ярдәмләшеп яшәргә, ирне – ир, туганны туган итеп, балаларга дөрес тәрбия биреп яшәүне өлге итеп, яшьләр үрнәк алсын иде...

Рамилә ГАЛӘҮТДИНОВА

***

Чын татар гаиләсе нинди дисәләр, Азат белән Эльмира гаиләсе кебек диярлек. Матур, ипле гаилә. Эльмираны төрле социаль челтәрләрдә күреп беләбез. Матур итеп сөйли, аңлата, балаларының кызыклы шуклыкларын матур итеп күрсәтә. Гөлгенә Шиһаповага да матур гаилә белән таныштыруы өчен рәхмәт. Менә бит үрнәк алырлык гаиләләр, яшьләр бар.

Зөлфия ГЫЙМАДИЕВА

14 август | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 15.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 16.30 «УЕННАН УЙМАК». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «СВАТЬИ». Телесериал 16+
11.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 Хоккей. Кубок TANECO. Матч за 3-е место. Прямая трансляция 6+
15.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
16.00, 00.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00 Хоккей. Кубок TANECO. Матч за 1-е место. Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Соотечественники». Телефильмы. «Старик Державин» и «Рашит Вагапов. Татарский соловей» 16+
00.25 «Каравай». Портрет современного фольклориста 6+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Утканнар сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Әхтәм Зарипов турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Мингалим турында телеочерк 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әнием белән жылы кочагы» 16+
00.15 «Ватандашлар» 16+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «ШТИРЛИЦ НАВСЕГДА». Рождение легенды 12+
21.00 «Время»
22.00 К 50-летию легендарного фильма. «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». Многосерийный фильм 12+
23.15 «Большая игра» 16+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Карина Андоленко, Илья Носков, Роман Маякин, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов. «СПАССКАЯ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». 12+
03.45 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Вы это видели» 12+
07.00, 09.30, 12.55, 21.30 Новости
07.05, 16.25, 19.00, 21.35, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.35, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.55 «Лучшие из лучших» 12+
10.55, 05.00 «География спорта. Камчатка» 12+
11.25 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 6+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 Регби. PARI Кубок России. 1/4 финала. «Красный Яр» (Красноярск) – «Металлург» (Новокузнецк). Прямая трансляция
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Алания» (Владикавказ) – «Торпедо» (Москва). Прямая трансляция
19.15 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Пари НН» (Нижний Новгород) – «Ахмат» (Грозный). Прямая трансляция
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Турнир «Вечерняя Москва». Прямая трансляция
00.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Палмейрас» – «Крузейро». Прямая трансляция
02.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Брагантино» – «Васко да Гама». Прямая трансляция
05.30 «Здоровый образ» 12+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Сергей Селин, Алексей Нилов, Александр Половцев в детективном сериале «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» (S) 16+
00.45 «Авторитеты» 16+
01.30 Алексей Кравченко и Сергей Селин в боевике «БРАТАНЫ» (S) 16+
03.00 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Холодная постель» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ГДЕ ЖИВЁТ НАДЕЖДА?» 16+
19.00 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА ФРАНЦУЗА» 16+
23.30 «Понять. Простить» 16+
00.45 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.45 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «ПРОВИНЦИАЛКА». 5-я – 8-я серии 16+
05.30 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «КЛАССНЫЕ ИГРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.10 «ДУМА О КОВПАКЕ». Телесериал. «НАБАТ» 12+
13.00 Торжественное открытие Международного военно-технического форума «АРМИЯ-2023»
13.25, 15.05, 17.15 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Противотанковые САУ». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «ЕДИНСТВЕННАЯ...» 12+
02.45 «И ТЫ УВИДИШЬ НЕБО» 12+
03.55 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

15 август | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «СВАТЬИ». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Современный национальный композитор. Лилия Тагирова 6+
00.50 «Соотечественники». Юнус Ахметзянов. Повар национального масштаба 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Утканнар сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Ватандашлар». Әхтәм Зарипов. Яшим, димәк, иҗат итәм 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30, 20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Мингалим турында телеочерк 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». Многосерийный фильм 12+
23.15 «Большая игра» 16+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Карина Андоленко, Илья Носков, Роман Маякин, Лариса Удовиченко, Михаил Жигалов. «СПАССКАЯ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анна Ковальчук в детективном телесериале «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.45 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Кто кого?» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.30, 14.55, 18.10, 21.30 Новости
07.05, 17.35, 21.35, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.35 Специальный репортаж 12+
09.55, 01.25 «Лучшие из лучших» 12+
10.55 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. 1/2 финала. Прямая трансляция из Новой Зеландии
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «География спорта. Камчатка» 12+
15.30 «ВИРАЖ» 12+
18.15 Футбол. Лига Европы. Финал. «Севилья» (Испания) – «Рома» (Италия). Трансляция из Венгрии 6+
20.35 «Вы это видели» 12+
22.30 Смешанные единоборства. UFC. Висенте Люке против Рафаэля Дос Аньоса. Трансляция из США 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Автоспорт. Российская Дрифт серия «Европа». Трансляция из Санкт-Петербурга 0+
04.00 Регби. PARI Кубок России. 1/4 финала. «Динамо» (Москва) – «Енисей-СТМ» (Красноярск) 12+

НТВ

04.40 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детективный сериал «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» (S) 16+
00.45 «Авторитеты» 16+
01.40 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Лужа» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ПРОПАСТЬ МЕЖДУ НАМИ» 16+
19.00 «СКВОЗЬ РОЗОВЫЕ ОЧКИ» 16+
23.30 «Понять. Простить» 16+
00.45 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.45 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 01.05 «ДУМА О КОВПАКЕ». Телесериал. «БУРАН» 12+
13.25, 15.05, 17.15 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Транспортная авиация». Премьера! 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «ПОД КАМЕННЫМ НЕБОМ» 12+
02.40 «Владимир Крючков. Последний председатель». Документальный фильм 12+
03.25 «Бой за берет». Документальный фильм 12+
03.55 «КОГДА РАСТАЯЛ СНЕГ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

ФИРДАНИЯБЕЗНЕ САГЫНАБЫЗ

Бу көннәрдә Әтнә районы халкына гына түгел, Татарстанга зур югалту килде. Олы Мәңгәр авылының мөхтәрәм кешеләре – Гаяз улы Мөбарәк, Фәрит кызы Фирдания, аларның нарасый сабыйлары Булат улы Аяз фаҗигале үлем белән арабыздан киттеләр... Искиткеч олы йортның хуҗалары, балалары Алиянең, Марсель белән Булатның терәкләре, киңәшчеләре, барлык оныкларының сөекле әби-бабайлары иде алар.

Бу зур югалту Фирдания белән Арча педагогия училищесын 48 ел элек тәмамлаган курсташларын да тетрәндерде: әле 24 июньдә генә кызы Алия белән Арчаның «Сабантуй» ресторанына барыбызны да җыеп, рәхәт, бәхетле очрашу оештырган иде. Укуны тәмамлавыбызның илле еллык юбилеена җыелырга теләп таралышкан идек...

Укыган вакытта ук яшүсмер Фирданиябез үзенең эш сөючәнлеге, сабырлыгы, ярдәмчеллелеге, көләч йөзлелеге белән күпләребездән аерылып тора иде.

Ә без, группадашлары, ничәмә еллар Фирданиянең киңәшләре белән яшәдек, ул җибәргән тәмле ризыкларның рецептларын кулландык (һәм куллана-чакбыз да). Киләчәктә ул бүләккә биргән җылы оекбашлар аякларыбызны гына түгел, күңелләребезне дә җылытып торыр дип өметләнәбез.

Вакытсыз гомере өзелгән дустыбызның якыннарының, туганнарының зур кайгыларын уртаклашабыз.

Әти-әниләренең матур эшләрен, гамәлләрен дәвам итүче балаларына, гомере вакытсыз өзелгән Аязның әти-әнисенә нык сабырлыклар телибез.

1975 елда Арча педагогия училищесын тәмамлаган 4Д төркеме

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

БАКЧАДАН УК БАШЛАНА

Җир йөзендә 2,2 миллиард чамасы кеше күз авыруларыннан интегә. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы китергән саннар шул хакта сөйли. Үзләренең һөнәри бәйрәмнәре алдыннан бер төркем күз табибы журналистлар белән очрашты. Аларның фикер, киңәшләрен укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәбез.

Бүген Татарстанда яшәүче 397 мең кеше күз авыруларыннан интегә. Аларның 97 мене узган ел ачыкланган. Шуларның яртысы диярлек (47 мең очрак) – балалар. Узган ел республикада 378 кеше күз авыруы аркасында инвалид дип табылган. Күз авыруларын ничек булдырмаска?

Елена ЖИДЕНКО, Республика клиник офтальмология хастаханәсе баш табибы урынбасары:

– Күз авырулары олысын да, кечесен дә аямый. Глаукома күз авырулары арасында иң җитдие санала. Инвалидлыкка китергән чирләр арасында да беренче урында тора ул. Макуляр дегенерация (күзнең арткы челтәр катлавы бозылу), күз нервы зәгыйфьләнү очраклары да еш күзәтелә. Балалар арасында исә шикәр чире вакытында күзәтелә торган күз авыруы (диабетик ретинопатия), глаукомалылар, ерактан начар күрүчеләр шактый. Күз авыруларын дәвалау ысуллары да елдан-ел камилләшә бара. Элегрәк шул ук глаукома дөм сукыраю котылгысыз булган мәкерле чир санала иде. Транссклераль циклофотокоагуляция алымы ярдәмендә хәзер аны да җиңә алабыз, кешенең күрүен саклап калабыз.

Илгиз ИСМӘГЫЙЛЕВ, Республика офтальмология клиник хастаханәсе баш табибының клиник-эксперт эше буенча урынбасары:

– Күзләр сәламәт булсын өчен, күбрәк җиләк ашарга кирәк. Кара җиләк (черника) аеруча файдалы. Җәен аны чиләкләп ашасаң да зыяны юк. Җир җиләге, кура җиләге, каен җиләгенең дә күзләргә шифасы әйтеп бетергесез зур. Бу хакта гел искәртеп килөбез. Киңәшләргә колак салучы гына сирәк. Күз сәламәтлеген гел контрольдә тотарга кирәк. Бер югалтсаң, аны кире кайтару бик авыр.

Ленара ХӘНИФӘТУЛЛИНА, Республика клиник офтальмология хастаханәсенең балалар күз табибы:

– Соңгы елларда ерактан начар күргән балалар саны артканнан-арта бара. Андыйлар хәтта балалар бакчасына йөргән сабыйлар арасында да очрый. Узган ел безгә барлыгы 140 меңгә якын бала мөрәҗәгать итте. Шуларның 70 меңенә миопия (ерактан начар күрү) диагнозы куелды. Якын киләчәктә бу пандемия дәрәҗәсендәге чиргә әверелергә мөмкин. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) белгечләре, 2050 елда Җир шарында яшәүче һәр ике кешенең берсе ерактан начар күрәчәк, дип фаразлый. Иң куркынычы шул: әлеге чир вакытында күзнең челтәр катлавы зарарлана, глаукома, катаракта кебек җитди чирләр килеп чыгу ихтималы арта. Бу исә, үз чиратында, кешенең тулысынча сукыраюына китерергә мөмкин. Ник дигәндә, миопия вакытында күз «озыная», шул рәвешле күзнең челтәр катлавы да сузыла.

Күзләр сәламәт булсын өчен, түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга кирәк:

✓вак рәсем, текстка текәлеп утырганда, күзләр бик нык ара. Шул сәбәпле еш кына кешенең күрүе дә начарлана. Шуңа күрә озак вакыт телефонга текәлеп, нидер карап, укып утырудан тыелырга кирәк. Балаларга да төрле мультфильм, кино, роликларны зур экраннан күрсәтсәң, яхшырак булачак;

✓күзләргә зыян килмәсен өчен, ноутбук яки компьютер экраны ким дигәндә 50–60 см, телевизор исә 2–3 метр ераклыкта булырга тиеш;

✓күзләрне ял иттереп алырга да онытмагыз. 40–45 минут компьютерда шөгыльләнгәч, 10–15 минут күзгә гимнастика ясап алыгыз. Моның өчен аскаөскә, сулга-уңга карарга, күзне түгәрәк буйлап әйләндерергә кирәк. Тагын бер ысул: тәрәзә янына килеп басыгыз да карандаш яки фломастер белән тәрәзәгә бер төртке төртегез. Еракка карап алгач, карашыгызны шул төрткегә юнәлтегез. Аннары кабат еракка карарга кирәк. Берничә тапкыр шулай эшләү күз мускулларындагы киеренкелекне бетерә;

✓йокы режимы бозылу күз нервына тискәре йогынты ясый. Шуңа күрә йокыгыз туйганчы йокларга тырышыгыз;

✓А, Е, С витаминнарына бай ризыклар (кишер, кара җиләк, брокколи, шпинат, җиләк-җимешләр, балык, фасоль һ.б.) ашагыз;

✓елга бер тапкыр булса да күз табибына күренеп кайтсагыз да зыян итмәс.

Күз авыруларының күбесе диспансеризация вакытында ачыклана, ди белгечләр. 2020 елда әлеге тикшеренүдән соң:

➤736 кешенең күзендә җитешсезлекләр барлыгы ачыкланган.

➤132 кешедә – глаукома, 140 кешедә катаракта табылган. 70 кешенең каршыдагы әйберләрне төгәл күрмәве билгеле булган.

Белеп тор!

Бил томса

300–400 грамм сарымсакны чистартып, иттарткычтан чыгарырга. Шуны 1 литрлы банкага салып, тулганчы үсемлек мае агызырга һәм ике атна караңгы урында тонәтергә, болгаткалап торырга кирәк. Аннары шуны 3–4 кат марля аша сөзеп, сарымсак маен остеохондроз кискенләшкәндә – билгә, артроз вакытында буыннарга сөртергә мөмкин. Полиэтилен пакет каплап, җылы шәл яки шарф белән төреп, төн буе тотарга кирәк. Бу процедураны хәл җиңеләйгәнче кабатларга ярый.

Табигать даруханәсе

ЯШЕЛ ШИФА

Белгечләр җәен җиләк-җимештән генә түгел, яшел тәмләткечләрдән дә шифа җыеп калырга өнди.

●**Сельдерей** А, В, К һәм Е витаминнарына бай. Анда протеин бар, шуңа күрә ул эчәклекләргә файдалы. Стресстан коткара, арыганда көч кертә, су-тоз алмашын җайга сала, хәтерне яхшырта.

●**Укроп**та В төркеме, С, А, Е, Р витаминнары, тимер, кальций, магний, фосфор күп. Ул кан тамырларын киңәйтә, баш мие эшчәнлеген яхшырта, ашказаны-эчәклек трактын авыруларыннан булыша.

●**Петрушка**да С витамины цитруслардан өч тапкыр күбрәк. Анда А, Р, Е витаминнары, фосфор, кальций, магний бар. Петрушка иммунитетны күтәрә, ашказаны-эчәклек трактын авыруларын кисәтә, организмнан артык сыеклыкны чыгара.

●**Руккола** клетчаткага бай, аппетитны кимәтә, нәтиҗәдә улябыгырга да булыша. Ашкайнату системасына файдалы, иммунитетны күтәрә, канда шикәрне кимәтә.

Яшел тәмләткечләр эфир майларына бай. Шуңа күрә аларны тәүлегенә 150 граммнан да артыграк ашарга киңәш ителми.

Саклап куй

Көчле ютәлдән компресс

Кирәк булачак: 1 аш кашыгы бал, 1 аш кашыгы горчица порошогы, 1 аш кашыгы аш серкәсе (уксус), 1 аш кашыгы көнбагыш мае, көлчә ясарлык он.

Эш тәртибе: барлык ингредиентларны он белән бергә бутап, көлчә ясыйбыз. Ике көлчә ясасагыз, бигрәк тә яхшы, чөнки аларны күкрәккә дә, аркага да куярга мөмкин булачак. Соңыннан әлеге көлчәләрнең берсен – күкрәккә, икенчесен аркага урнаштырып, киҗе-мамык тукыма яки шәл белән урап куябыз. Һәм йокларга ятабыз. Иртәнгә ютәлнең эзе дә калмас.

Үзем сынадым

Аяк тирләүдән

Ирем аягы тирләүдән интегә. Соңгы елларда аяктан ис килүдән җайлы гына ысул ярдәмендә котыла башлады. Һәр көнне кич белән аякларны 10–15 минутка шалфей төнәтмәсе белән аш тозы (ярты табак җылы суга бер уч тоз) кушылган суга тыгып утыра. Файдасы шундук сизелә.

Әлфинур ВӘЛИЕВА.
Казан

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

СЫНАЛГАН РЕЦЕПТЛАР

Бакчадагы нигъмәтләрне банкаларга тутырып, кышка тәмледән-тәмле ризыклар ясап куяр вакыт. Шуңа күрә хуҗабикәләр, буш вакыт тидеме, аш бүлмәсенә төрле «тәмлүшкә»ләр ясарга ашыга. Аларның әшен бераз гына җиңеләйтү өчен, үзебез әйбәт дип тапкан яңа рецептларны җыеп тәкъдим итәргә булдык.

Помидордан

БАКЛАЖАНЛЫ САЛАТ

НУРЛИСӘ ШИҺАПОВА РЕЦЕПТЫ

Кирәк булачак: 2,5 кило помидор, уртача зурлыктагы 8 кишер, 3 баклажан, 6 татлы борыч, 200 г үсемлек мае, 1 әче борыч, 2 баш сарымсак, 200 г шикәр комы, 1 аш кашыгы (өеп) тоз.

Помидорны – иттарткычтан, кишерне – эре тишекле угычтан чыгарабыз. Баклажанны, татлы борычны – озынча итеп, әче борычны, сарымсакны ваклап турыйбыз. Помидорны зуррак кәстрүлгә салып, 15 минут кайнатабыз. Кишер, тоз, шикәр комы, май өстәп, тагын 15 минут кайнатып алабыз. Шуннан баклажан, татлы борыч, әче борычны салып, тагын 15 минут утта тотабыз. Ахырда сарымсак һәм 4 аш кашыгы аш серкәсе өстәп, 3–4 минут кайнатабыз. Парландырылган банкаларга тутырып, өстен тимер капкач белән борып ябабыз.

Аджика

РӘМЗИЯ ГАЛИЕВА РЕЦЕПТЫ

Кирәк булачак: 3 кило помидор, 1 кило татлы борыч, 2–3 әче борыч, 2 баш сарымсак, 500 г томат пастасы, 1 стакан үсемлек мае, 2 аш кашыгы тоз, 3 аш кашыгы 9 процентлы аш серкәсе яки ярты касә 6 процентлы алма серкәсе.

Помидорны иттарткыч аша чыгарабыз. Кәстрүлгә помидор, үсемлек мае, томат пастасы салып, 30 минут кайнатабыз. Шуннан татлы борыч, әче борыч, сарымсак (барысын бергә иттарткыч аша чыгарасы) өстәп, тагын 15 минут утта тотабыз. Аш серкәсе яки алма серкәсе салып, барысын бергә болгатабыз да парландырылган банкаларга тутырабыз.

«Айвар» соусы

ДИНӘ ӘХМӘДИЕВА РЕЦЕПТЫ

Кирәк булачак: 1 кило помидор, 1 кило татлы борыч, 5 әче борыч («яндырганны» яратмасагыз, әзрәк салырга мөмкин), 500 г башлы суган, 3 тырнак сарымсак, 60 г тоз, 60 г шикәр комы, 30 г үсемлек мае, 10 г аш серкәсе (9 процентлы), 1 аш кашыгы горчица пастасы.

Барлык яшелчәне иттарткыч аша чыгарабыз. Кәстрүлгә тутырып, тәмләткечләр өстибез дә 30–40 минут пешерәбез. Банкаларга тутырып, тимер капкач белән борып ябабыз. Банкаларны, суынганчы, җылы әйбер белән каплап тотабыз.

Кышка «кекс»лар

ГҮЗӘЛ ӘХМӘТҖАНОВА КИҢӘШЕ

Помидор – черек товар, диләр. Череп әрәм булмасын өчен, аннан менә дигән тәмләткеч әзерләргә мөмкин. Бу очракта помидорларның итлерәкләре әйбәт. Кабыгын чистартып, вак кисәкләргә турыйбыз да, кәстрүлгә салып, согы парга әйләнсен өчен, капкачын япмыйча гына салмак утта 1,5–2 сәгать пешерәбез. Шушы вакыт эчендә согынның 2/3 өлеше юкка чыга. Помидор куергач, тәменчә тоз, борыч, башка тәмләткечләр (нәрсә ошый – шуны) өстәп болгатабыз һәм уттан алабыз. Кекс өчен дигән силикон савытларга тутырып, туңдыргычта катырабыз. «Кекс»лар каткач, целлофан капчыкка тутырабыз.

Кыярдан

Әчкелтем-татлы салат

РОЗА АНАНЬЕВА РЕЦЕПТЫ

0,7 литрлы 3 банка өчен кирәк булачак: 1,5 кило кыяр, 1,5 л су, 200 г шикәр комы, 250 мл 6 процентлы алма серкәсе, 3 аш кашыгы тоз, 2 аш кашыгы горчица орлыгы, 6 хуш исле түгәрәк борыч, 3 дәфнә яфрагы.

Кыярны юып, салкын суга салабыз һәм 1 сәгатькә калдырып торабыз. Шушы вакыт эчендә банка һәм капкачларны юып-парландырып алабыз. Кыярны 2 см чамасы киңлектә боҗралап турыйбыз. Кәстрүлгә су, шикәр комы, тоз, горчица орлыгы, дәфнә яфрагы салып, кайнап чыкканнан соң 2–3 минут утта тотабыз. Аш серкәсе өстәп, тагын кайнатып чыгарабыз. Кайнап торган маринадка кыяр салып, кайнатып чыгарабыз һәм, болгата-болгата, тагын 2–3 минут пешереп алабыз (кыярның төсе үзгәрергә тиеш). Кыярны банкаларга тутырып, 2шәр түгәрәк борыч өстибез, тозлыгын банка авызына җиткереп салабыз һәм капкач белән борып ябабыз. Банкаларның астын өскә әйләндереп куябыз да суынганчы җылы әйбер каплап тотабыз.

Тозлау

МӘРЬЯМ МИҢНЕГУЛОВА РЕЦЕПТЫ

Иң элек банкаларны парландырып чистартабыз. Төбенә укроп сабаклары салабыз, кыярларны юып тутырабыз. Кайнап торган су агызабыз. 15 минут тоткач, суны түгәбез.

Аерым савытта 4 литр суга ярты стакан тоз, 1 стакан шикәр комы (200 мл), 1 стакан 9 процентлы аш серкәсе салып, тозлык ясыйбыз. Кыярлы банкаларга тәмләткечләр: түгәрәк кара борыч, хуш исле борыч, канәфер өстәгәч, тозлыкны салабыз да тимер капкач белән борып ябабыз. Банкаларның астын өскә әйләндереп, өстенә җылы әйбер ябабыз һәм, суынгач, саклауга алып куябыз.

Кетердәп торган салат

РЕЗЕДӘ САДЫЙКОВА РЕЦЕПТЫ

Яртышар литрлы 8 банка салат ясау өчен кирәк булачак: 4 кило кыяр, 1 кило башлы суган, 4 кишер, 6–7 тырнак сарымсак, ½ әче борыч, кечкенә генә укроп бәйләме, ярты стакан шикәр комы, 2 аш кашыгы тоз, 8 түгәрәк кара борыч, 200 мл 9 процентлы аш серкәсе, 200 мл үсемлек мае.

Суганны – ярымбоҗра рәвешендә, кыярны 0,5 см киңлектә боҗралап турыйбыз. Укроп, сарымсак һәм әче борычны – ваклап, кишерне озынча рәвешкә китереп турыйбыз. Барысын бергә кәстрүлгә тутырабыз. Шикәр комы, тоз һәм түгәрәк борыч, үсемлек мае, аш серкәсе өстибез. Барысын бергә болгатып, 20–30 минутка калдырып торабыз. Кайнап чыккач, 10 минут пешерәбез. Яшелчәне парландырылган банкаларга суы белән бергә тутырабыз һәм тимер капкач белән борып ябабыз.

Борычтан

БАЛЛЫ МАРИНАДТА – ҖӘЙ ТӘМЕ

НИНА ВАСИЛЬЕВА РЕЦЕПТЫ

Кирәк булачак: 3 кило татлы борыч (төрле төстә булса яхшырак). Маринад өчен: 2 стакан су, 150 мл 9 процентлы аш серкәсе, 1 стакан бал, 1 аш кашыгы үсемлек мае, 2 аш кашыгы тоз.

Борычны юып, чистартып, зур өлешләргә бүләбез. Суга аш серкәсе, бал, май һәм тоз салып, маринад кайнатабыз. Балы эрегәч, тагын 2 минут кайнатып алабыз. Татлы борычны салып, болгата-болгата 5 минут кайнатабыз. Газ утын сүндермичә, борычны тишекле чүмеч белән кәстрүлдән алып, парландырылган банкаларга тутырабыз. Маринад салып, тимер капкач белән борып ябабыз.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

КИТҮНЕ ДӘ УЙЛАМЫЙ БУЛМЫЙ

Өч көнлек дөньяда яшибез. Кыска гына шушы гомерендә адәм баласы шатлыгын гына түгел, борчу-хәсрәтен дә күп күрә. Шуңа өстәп, әледән-әле төрле хәвеф-хәтәрләр, табигать бәла-казалары да булып тора. Соңгы арада бигрәк тә ешайды алар. Нәрсә бу: тәкъдирме? Аллаһы Тәгаләнең бер сынавымы? Әллә инде үзебезнең ваемсызлык нәтиҗәсеме?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әлеге һәм башка сораулар белән «Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Ансар хәзрәт МИФТЯХОВка мөрәҗәгать иттек.

:: Соңгы арада хәвеф-хәтәрләр, табигый бәла-казалар, үлем-китемнәр бик нык артты. Күпләр моны, ахырзаман галәмәте, ди. Бу фикер белән килешәсезме?

– Соңгы арада мәчетләргә дә шундый сорау белән еш мөрәҗәгать итә башладылар. Төрле җир тетрәүләр, табигать бәла-казалары арту динебездә, дөрестән дә, ахырзаманның бер билгесе санала. Гомумән, соңгы елларда ахырзаманның акрынлап якынлашуы, төгәлрәк әйтсәк, аның кече билгеләре күренә башлады. Пәйгамбәребезнең хәдисендә: «Кыямәт көне алдыннан бер ел – бер атна, бер атна бер көн кебек үтәр, бер көн бер сәгать кебек тоелыр», – диелә. Шул рәвешле вакытның тизләнүе кыямәт көне якынлашуның чираттагы бер билгесе булып тора. Хәмер куллану, зина кылу кебек олы гөнаһларның артуы да бу көн якынлашуга ишарәли. Пәйгамбәребез шул ук хәдисендә: «Кыямәт көне якынлашканда, ирләрнең саны кимер, хатын-кызларныкы артыр», – диелә. Биек-биек йортлар төзелү, үлем-китем очраклары арту да кыямәт көненең кече билгеләре булып тора. Пәйгамбәребез хәдисендә: «Ата-аналар үзләре белән идарә итүче уллар тудырырлар», – дигән юллар да бар. Бүген, дөрестән дә, күп очракта бала ата-анасы белән идарә итә бит.

:: «Өч көнлек дөнья» дибез. Борынгылар ни өчен шулай диде икән? Диндә моның берәр аңлатмасы бармы?

– Бер нигезсез барлыкка килгән сүзләр түгел бу. Ислам динендәге борынгы галимнәребез дә шулай дип әйтә торган булган. Хәсән Әл-Басрый дигән галим: «Дөнья өч көннән тора: кичә, бүген, иртәгә. Кичәге көн инде үтеп китте. Иртәгә синең өчен килеп тә җитмәскә мөмкин. Синең көнең ул – бүген. Аны иң яхшы һәм кыйммәтле рәвештә кулллан», – дигән. Шуңа күрә без бүгенге көнебез белән яшәргә тиеш. Пәйгамбәребез дә бер хәдисендә: «Дөньялыгыгызны кайгыртыгыз – мәңге яшим сыман. Ахирәтегезне кайгыртыгыз – бүген бу дөньядан күчәм сыман», – ди. Ягъни дөньялыкны кайгыртканда, гаилә дә булдырырга, балалар табып, байлык та тупларга, йортын да төзергә, эшләргә дә – кыскасы, мәңгелеккә килгән кебек яшәргә кирәк. Ә инде ахирәтеңне кайгыртканда, ягъни намаз укыганда, ураза тотканда, сәдака, зәкят биргәндә, корбан чалганда, ахыр дөнья турында уйларга кирәк. Һәр гамәлеңне соңгысы кебек, тырышып башкарырга кирәк.

:: Давыл, гарасат, яшен сугу кебек табигать бәла-казалары вакытында вакытсыз гомере өзелгән кешеләрнең гөнаһлары кичерeләме?

– Аллаһы Тәгалә безне яраткан һәм якты дөньядан китүебез дә, җәннәткә эләгүэләкмәвебез дә – барысы да Аллаһы Тәгаләдән. Гамәлләребез, гыйбадәтләребез дә бары тик аңа гына мәгълүм. Бар нәрсә кешенең ниятеннән тора. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Һәр гамәл ниятләр белән кабул ителә», – ди. Давыл, гарасат, яшен сугу кебек табигать бәла-казалары вакытында вакытсыз гомере өзелгән кеше дә изгелекләре, гыйбадәтләре күп булып, кыямәт көнендә үз гөнаһлары өчен җавап бирә алганнан соң гына җәннәткә эләгәчәк. Шул ук яшен суккан вакытта бу кеше нинди гамәлдә булган? Спиртлы эчемлек алырга яисә явызлык кылырга барышы булганмы аның? Әллә инде шушы табигать бәла-казасы вакытында ул мәчеткә юл алган булганмы? Кешенең җәннәткә эләгү-эләкмәве әнә шуңа да бәйле.

:: Яшен яшьнәгәндә әбиләр, «бисмилла» әйтеп, бөтен гәүдәне сыпырырга куша иде. Янәсе, шулай эшләсәң, кешене яшен сукмаячак. Бу – ырым-шырым гынамы? Әллә моның дини яктан берәр аңлатмасы бармы?

– Пәйгамбәребез «Фатиха», «Аятел-көрси», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен укып, кулына өреп, тәнен сыпыра торган булган. Төрле авырулардан котылу, төрле бәла-казалардан саклану өчен дә шулай эшләгән ул. Яшен яшьнәгәндә, «бисмилла» әйтеп, тәнне сыпыру гадәте дә шуннан килә.

:: Көндәлек тормышыбызда, бигрәк тә җәйге чорда ике көннең берендә диярлек төрле хәвеф-хәтәрләр, юл фаҗигаләре, табигать бәла-казалары килеп чыгып тора. Аларда могҗиза белән исән калучылар да була. Бу – кешеләрнең гомерләре бетмәгән дигән сүзме? Мондый могҗизалы исән калу очраклары кешенең язмышына алдан язылган буламы?

– Бәла-каза килү, нинди дә авырлыкларга очрау – барысы да Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сынау. Аннан исән калу – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте. Гомере бетмәгән бәндәгә Аллаһы Тәгалә үзенең бер ярдәмен күрсәтә. Без бу дөньяга кайчан килгәнебезне белмәгән сыман кайчан китәсебезне дә белмибез. Аллаһы Тәгалә адәм баласына гомернең бер чиген биргән икән, без ул чиктән бер минутка артык та, ким дә яши алмыйбыз. Кайда язылган булса, җаныбыз шул җирдә чыга. Бу – тәкъдир. Аны берничек тә үзгәртеп булмый. Шуңа күрә кешегә Аллаһы Тәгалә биргән гомергә разый булып, могҗиза белән исән калган очракта тәүбә кылып, булган гыйбадәтләрен дәвам иттерергә кирәк. Әгәр кеше әле намазда түгел икән, бәлки бу могҗизалы исән калу – Аллаһы Тәгаләдән моны эшли башларга вакыт җитүгә, күзеңне ачуга бер ишарәдер? Адәм баласы дин юлына шатлыкта гына түгел, авыр вакытларда да килә.

:: Билгеле, адәм баласы шундый гадәттән тыш хәлләр белән сынала да. Бу сынаудан без нинди нәтиҗәләр ясарга тиеш?

– Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Мин сезне курку, ачлык, ялангачлык белән, байлыкларны, туганнарыгызны биреп-алып, уңышны күп итеп биреп һәм әзәйтеп сынармын. Бу сынаулар Аллаһы Тәгаләдән булды дип инанып, аңлап, шуңа сабыр булган бәндәләргә мин Үземнең шатлыгымны, сөенечемне, иркен тормышымны да насыйп итәрмен», – ди. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләнең биргән сынауларына сабыр булып, кушканнарын үтәп, тәүбәгә килеп, булган нигъмәтләребезгә шөкрана кылып яшәргә тиеш. Юкса, күп кеше сынауларның Аллаһы Тәгаләдән бирелүенә инанмый. Чынлыкта, коры еллар да, җил-давыл, хәсрәтләр дә, мәшәкать-борчулар да нәрсәнедер дөрес эшләмәвебездән, Аллаһы Тәгаләнең безгә ачуы килүдән була. Шуңа күрә Ходай биргән гомеребезне Аллаһы Тәгаләдән разый булып, ул биргәннәргә шөкер итеп яшәргә кирәк. Шул вакытта гына киләчәктә сөенечләргә ирешербез.

Гыйбрәтле кыйсса

Тәрәзә ник ватыла?

vk.com

Бервакыт остаз өч шәкерттән сораган:

– Таш ыргытсаң, тәрәзә пыяласы ни өчен ватыла?

– Чөнки таш авыр, – дигән бер шәкерт.

– Пыяла юка булганга, – дип җавап биргән икенчесе.

Өченчесе:

– Ташны кизәнеп ыргытканнар, – дип фаразлый.

– Өчегезнең дә җавабы дөрес түгел, чөнки тәрәзә ябык булган. Йөрәгегез кешеләргә һәрвакыт ачык булса, аны беркем дә таш ыргытып, чәлпәрәмә китерә алмас, – дигән остаз.

Йәгез, бер дога!

ЯШЕН ВАКЫТЫНДА УКЫЛА

«Аллаһүммә, лә тактульнә бигадабикә, уә лә тухликнә бигазабикә, уә гафина кабләзәликә».

– Төп офисыбыз Казанда безнең. Гел барып йөрибез. Залесныйга җиткәч, таш каланың эченә кермичә, кире әйләнеп китәсе килә. Заманында бераз җитәкчеләр белән каршылыклар булып алса да, Апасны ташлап китә алмадым, яңадан әйләнеп кайттым. Дөрес, үзем Чүпрәле районының Иске Шәйморза авылында туганмын. Ике яшьлек чагымда әнием монда күченеп кайткан. Мине аякка бастырыр өчен бик тырышты инде, көн-төн эшләде. Әле дә хәтеремдә: иске генә йортыбызның тәрәзәләре яртылаш җиргә сеңгән иде. Миңа я сарык, я каз бәбкәләре алып кайтып куяр иде дә: «Улым, мә, үстер», – дип әйтер иде. Укытты, кеше итте ул мине. Институтта математик һөнәре алып чыктым. Тик ул юнәлеш буенча бик аз эшләдем. Ниндидер зуррак эшләргә тотынып, тормышны бар итәсе, әнине рәхәттә яшәтәсе килде. Ул гына дөньяны иртәрәк калдырып китте. Вафат булганына 22 ел инде.

:: Балаларыгызны әни үрнәгендә тәрбиялисезме?

– Нәкъ шулай. Эшләп кеше үлми, дип әйтә иде әнием. Гомумән, без тормышны гаиләбез белән бергә күтәрергә күнеккән. Хәләл җефетем Гөлнара – «Шерхан» дип аталган үз кафебызда директор. Юлчылар аптырап йөрмәсен өчен, 9–10 кешелек кунакханә дә төзеп куйдык. Янәшәдә генә автосервисыбыз бар. Машиналарын шунда куялар, ремонтлап алалар. Сыйфатлы эшләгәч, тирә-юньнән мөрәҗәгать итүчеләр дә күп. Кызым Әдилә быел 11 нче сыйныфны тәмамлады. Юрист булырга хыялланa. Укырга байтак вакыт бар бит әле. Иртәдән кичкә кадәр әнисе янында кафеда эшләп йөри. Улым Раил 9 нчы сыйныфны тәмамлады, автосервисның бер бинасында келәмнәр юа. Уйнап кына башлаган идек, баксаң, келәмне чистартырга теләүчеләр искиткеч күп икән. Китереп кенә торалар. Мин башлаган эшләр белән бик кызыксына. Эшемне дәвам итүче бар, димәк. Шуңа күрә күңелем тыныч.

:: Бизнес бер аякта гына басып тора алмый дигәннәрен бер дә онытмыйсыз, ахры?

– Теләсә нинди бизнесның көннәрдән беркөнне кителә торган гадәте бар. Ахыр чиктә, дүрт аяклы сыер да абына, диләр бит. Менә шул вакытта аякка басып китәр өчен кирәк булырга бик мөмкин ул.

:: Сезнең хакта кешеләр, бик ярдәмчел, юмарт, башкаларга хәерхаһлы, дип сөйлиләр. Шулкадәр зур хезмәт куела бит. Хәләл малны таратырга җәл түгелме?

– Мин таратмыйм бит. Үз көчем белән тапкан мөлкәтемнән, үз кесәмнән мохтаҗ булган кешеләргә өлеш кенә чыгарам. Әле менә коллективыбызда бер шофер үлеп киткән иде. Гаиләсе бик авыр хәлдә калды. Аларны ничек язмыш кочагына ташлап калдырасың? Дини бәйрәмнәрдә бәрәннәр чалып, коллективыбызга да, аларның гаиләләренә дә өлеш чыгарам. Мәчет белән дә араны өзмим. Бу вакытларга күбрәк әниемне искә алам. Сыйныфташлар килеп чыккалый. Бер машина ком, азрак төзелеш материаллары, тегесен-бусын гозерләп килгән кешегә булышырга тырышам. Махсус хәрби операциягә киткән егетләребез турында да онытмыйбыз.

:: Эшли торгач, ял итәргә онытып җибәрмисезме?

– Менә монысы – чыннан да, проблема. Гаилә белән ял итәргә дип, урманда йорт салып, умарталар да үрчеткән идек. Баксаң, быел барып карарга да вакытым тимәгән икән бит. Хатаны төзәтергә, Төзүчеләр көнендә булса да, ял итеп кайтырга кирәк булыр. Форсаттан файдаланып, хезмәттәшләремне бәйрәм белән котлыйм. Барыбызга да исәнлектә, иминлектә яшәргә язсын!

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА



ak-bars.ru

ҮЗЕБЕЗНЕҢ КЕШЕ

«ХОККЕЙДА КАЛАСЫМ КИЛӘ»

Очрашу алдыннан Данис ЗАРИПОВ журналистларның сорауларына җавап бирде.

– Титулларыгыз, уңышларыгыз күп. Аеруча кайсы белән горурланасыз?
– Тырышлыгым белән горурланам. Җиңүләремнең барысына да зур хезмәт ярдәмендә ирештем. Алдамадым, хәйләләмәдем, җиңел юл эзләмәдем. Кулдан килгәнчә тырышып эшли алуым өчен үземә рәхмәт әйтәм.

– Алга таба нәрсә булачак, быелгы ялыгыз кайчан тәмамлана?
– Күрәсең, миңа да ял итәргә вакыт җиткәндер. Сер итеп кенә әйтәм: 10га яки 11гә кадәр йоклауның, аннары берни эшләмәүнең бер авырлыгы да юк икән. Мәшәкатьләр бар анысы. Әмма мондый вакыт озакка сузылмаска да мөмкин. Аннары ни буласын күз күрер. Әлегә озакка сузылган карьерамнан соң хәл алам. Клуб белән элемтәдә торабыз. Якын арада җитәкчелек белән утырып сөйләшәчәкбез. Хоккейда каласым, Татарстан хоккееның үсешенә өлешемне кертәсем килә.

– «Металлург» яки «Ак барс»та тренер булырга тәкъдим итсәләр, кайсын сайлар идегез?
– Тамчы да икеләнмичә «Ак барс»ны.

Казан бер кичкә Россиянең хоккей үзәгенә әверелде. Әлеге вакыйганың үзәгендә исә Данис Зарипов кайнады. Соңгы елларда татарның иң танылган спортчысына әверелгән хоккейчының саубуллашу матчына илнең иң яхшы алка сугучылары җыелды. Овечкин белән Мозякин, Ковальчук белән Дацюк һәм башкалар катнашкан тамашада матур сүзләр әйтелде, күз яшьләре чыкты һәм мондый нәтиҗәгә килделәр: яңа тормыш әле башлана гына. Ни эшләргә җыенганын төгәл әйтмәсә дә, Данис хоккей белән араны өзмәячәген сиздерде.

Халык спортчыны яратып кабул итсен өчен, рекордлы очколар, зур җиңүләр генә җитми. Үз кеше булырга кирәк. Данис әнә шундый кешегә әверелде. Хәтта кайбер тамашачы аның Чиләбедә туып-үскәнен дә белми. Тәп матч башланыр алдыннан легендар хоккейчы белән бозга әнисе, хатыны һәм ике улы да чыкты. Зарипов ирешкән уңышлары өчен кемнәргә бурычлы булуын искә алды. Әтисе Зиннурның аны ничек итеп хоккей белән таныштыруы, беренче көнегүдә ике адым атлагач егылуы, әмма гомере буе кулыннан кәшәкә төшмәве турында сөйләде.

Көн узган саен алкага яхшырак суккан, инде Канадага барып, осталыгын чарлаган яшь уенчыны көннәрдән бер көнне Казанга чакыралар. Ә өйгә кайтып, бу хакта әйткәч, әнисе Фаиләдән мондый җавап ишетә: «Улым, мин инде күптән Казанга кайтырга җыенам».

Яшь Данисның «унлы» машинасында мавыктыргыч сәяхәт башлана. Башта Чиләбедән Алабугага кадәр кайталар. Аннары Казанга кадәр юлны күрсәтергә дип, авылдан туганнарын кереп алалар. Барып җитәләр, килешү төзелә, ә менә бозда үзенә юл яру җиңел булмый. Яшь егет хәтта кабат Чиләбе ягына да каера башлый. Бәхетенә, сабыр итәргә киңәш бирүче табыла. Нәкъ менә шул сабырлыгы, үҗәтлеге һәм үзсүзлелеге аркасында мәшһүр хоккейчы үсеп чыкты да Данистан. Ул беркайчан да тизлеге белән алдырмады, көндәшен бәреп егарлык көчкә ия булмады. Уңышка ирешүнең башка юлын тапты: акыл белән уйнады.

Боздагы осталыгы – бер хәл, татар егете булган өчен тагын да ныграк яраттылар Зариповны. Соңгы елларда татарның иң танылган спортчысына, үзе дә сизмәстән милләтнең горурлыгына әверелде ул. Малайлар үрнәк алды, әбиләр дога кылды. «Ак барс»та булмаса, мондый игътибарга, мондый уңышка ирешер идеме Данис?

Хәзер инде бу сорауга җавап эзләүнең мәгънәсе юк. Зарипов дигәч – «Ак барс», ә «Ак барс» дигәч, Данис күз алдына килә.

Әмма тормышта мәхәббәт белән генә яшәп булмый. 2013 елда Даниска Казаннан китәргә туры килде. Кем әйтмешли, «яратып китеп кара». Магнитогорскида ул янә чемпион булып танылды, яңа рекордлар куйды, ике тапкыр Гагарин Кубогын отты. Әмма барыбер Казанга тартылуын яшермәде. Киткәндә бер авыр булса, кайтканда янә сынау аша узарга туры килде. Хоккейчыны допинг куллануда гаепләгәч, аңа «Татнефть», ягъни Татарстан ярдәм кулы сузды. Һәркемгә мондый мөнәсәбәт күрсәтмиләр. Ә ул – үзебезнең кеше. Шуңа күрә аның өчен аерым хоккей бәйрәме оештырылды. Бәйрәмнең иң тантаналы өлешендә аның фамилиясе язылган свитерны «Татнефть Арена» түбәсенә күтәргәч, моннан ары «Ак барс»та беркемнең дә 25 саны астында чыгыш ясамаячагын игълан иттеләр. Бу урында яшь кызлар гына түгел, күпне күргән ир-егетләрнең күз яше чыкты. Кабат андыйлар булмаячак. Зариповның кабатланмас кеше икәнен Россия Хоккей федерациясе президенты Владислав Третьяк, «Ак барс» президенты Наил Мәганов, Казан мэры Илсур Метшин, Татарстанның спорт министры Владимир Леонов та әйтте.

Хәзерге вакытта Россиянең иң шәп хоккейчысы саналган Александр Овечкинның фамилиясе язылган һәм саубуллашу матчында чыгыш ясаган уенчыларның имзасы салынган свитерны, тамашачылар арасында аукцион уздырып, 2 миллион 100 мең сумга саткач, бозга Зарипов һәм иптәшләре чыкты. Нинди җиңүләргә ирешкәннәрен санап бетерерлек түгел. Овечкиннан тыш, саубуллашу матчында Павел Дацюк, Илья Ковальчук, Сергей Мозякин, Александр Семин, Евгений Кузнецов, Александр Радулов һәм башкалар уйнады. Бу кадәр «йолдыз»ны бер урынга Данис кына җыя ала. Беренче периодта ул «Яшелләр» командасында Алексей Морозов һәм Сергей Зиновьев белән бергә чыгыш ясады. Атаклы ЗЗМ! Виталий Прошкин, Александр Степанов, Евгений Медведев, Григорий Шафигуллин да шунда. Ә икенче периодта «Аклар» ягына күчеп, энесе Марат һәм улы Артур белән бозга чыкты. Очрашуда соңгы алка Зариповныкы булырга тиеш иде. Шулай булып чыкты да. Артур пас бирде, Данис кертте һәм янә кулына микрофон алып, хоккей сөючеләргә дәште: «Мин сезне яратам һәм алга таба да яратачакмын».

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Зиннәтулла БИЛАЛЕТДИНОВ, «Ак барс»ның баш тренеры:
– Яраткан шәкертләрем күп. Зарипов, Морозов, Никулин һәм башка бик күпләр... Мондый уенчылар белән эшли алганым өчен үземне бәхетле саныйм. Данисны аеруча яратам. Алар барысы да – үзенчәлекле шәхесләр. Данис белән тренерлык эше турында сөйләшеп карадым, әмма ул җавап бирмәде. Мин инде күп эшләдем, ә менә аңа ярдәм итәр идем.

ДАНИС ЗАРИПОВНЫҢ КАЗАНЫШЛАРЫ – САННАРДА

1996–1998, 1999–2001 – «Мечел»

1998–1999 – «Свифт Каррент Бронкос» (Канада)

2001–2013, 2017–2023 – «Ак барс»

2013–2017 – «Металлург» (Магнитогорск)

Карьерасы 24 ел 362 көн – 2023 елның 24 февраленә кадәр дәвам итте

Россия чемпионатларында **1324** матч, **431** алка, **546** пас

«Ак барс»та **18** сезон, **928** матч, **292** алка, **356** пас

Россиянең 6 тапкыр чемпионы (2006, 2009, 2010, 2014, 2016, 2018). Әлегә бердәнбер 5 мәртәбә Гагарин Кубогы иясе (2009, 2010, 2014, 2016, 2018). 3 тапкыр дөнья чемпионы (2008, 2009, 2014). Дөнья чемпионатларының көмеш (2015) һәм бронза (2007) призеры.

УРТАК ЯЗМЫШ

Икең бербөтен булып яшәп була икән. Игезәкләр булсаң... Башкалар ничектер, ә менә Казан кызлары Эльмира һәм Эльвира Эркимбековалар бер-береннән башка яши алмый. Берсе авырса, икенчесе моны шундук сизә. Бер карында үсеп, бергә якты дөньяга килгән кызларның бөтен тормышлары да охшаш. Алар хәтта кияүгә дә бер йортка, абыйлы-энеле егетләргә чыгалар.

Эркимбековаларның гаилә архивыннан

«Әни җитми!»

Эльмира белән Эльвираны тыңлап торасың да шаккатасың. Әти-әнигә хөрмәт, туганнарны ярату хисләре ташып тора. Алар гел бергә. Бер генә бәйрәмне дә калдырмыйлар, әтиләре янына атна саен кайтып йөриләр. Әниләренең вафатына – 4 ел.

– Әти белән әнинең яшь аермасы 4 ел иде. Әти әнине күргән дә гашыйк булган. Ул чакта әниемә 18 дә тулмаган. Май аендагы туган көнен көтеп торган да, ун көннән соң өйләнгән дә куйган, – ди Эльмира. – Алар бер-берсен бик яратып яшәде. Әни акыллы хатын иде. Безгә дөрес тәрбия бирде. Гайбәт сөйләмәде. Кешене хөрмәт итәргә өйрәтте. Безнең гаиләдә әтигә ихтирам аеруча зур иде. Әти кырыс төсләрәк күренсә дә, тиз кайтып төшәр иде. Әни аны өйрәнеп беткән иде инде. Бераздан барысын да рөхсәт итәсен белә иде.

Ренат абый белән Гөлниса апа 41 ел бергә гомер итәләр. Уллары Риналь туганны 5 ел көтәләр. Аңа ике яшь вакытта игезәк кызлар дөньяга килә. 2011 елда хатында яман чир табалар. Әмма ул чир белән озак көрәшә әле.

– Башта күкрәгендә шеш таптылар. Табиблар начар чир икәнен шундук әйтте. Операция ясадылар. Ярты елдан соң әнинең кулы авырта башлады. Кая гына бармадык, кемгә генә күрсәтмәдек. Әни өч ел интекте. Кулына тотынып та булмый иде. Эльвира белән тамада булып йөргән чак. Абыем белән киңәшеп, җаен таптык. Аптырагач, башка төбәктәге табибларга күрсәттек. Алар операция вакытында әнинең бөтен бизләре дә алынып бетмичә калуын, инде чирнең тагын таралуын әйтте. Күрәчәктер инде, теге вакытта әнигә операция ясыйсы табиб урынына яшь егетне билгеләгәннәр икән. Ә ул ике лимфа төенен алып бетермәгән, – дип искә ала Эльмира. – Әни яңадан урынга ауды. Кулда табиб хатасы дигән язу да бар. Әшне зурга да җибәрмәкче идек. Әнием туктатты. Ул бик дини иде. Аллаһы Тәгалә шулай язган, димәк, диде. Баксаң, ул яшь хирургка әни үзе операция ясарга ризалык биргән икән. Әнине яшәтәсе килде. Мәскәүгә өч алып барып дәвaладык. Әни үзе дә арыды. 2019 елның 2 мартында абый өйләнде. Әнигә көчле укол ясадык. Ул бар авыртуын онытып, туйда утырды. Аннан соң тагын авырайды. Җибәрегез мине, диде. Безнең белән сөйләште. Бөтен кеше белән бәхилләште дә китеп барды. Туганнар аның янынннан китмәде. Алар акчалата да булышты безгә. Әле дә әнине искә алып, безне бик якын итеп торалар.

Эльмира никадәр көчле булырга тырышса да, әнисе турында сөйләгәндә күзләре яшьләнә. Өзелеп сагынуын яшерми ул.

– Әнисез тормышка ияләнү читен булды. Без әле дә яшәргә өйрәнәбез. Тормыш төрлечә сынады. Тезләндергән чаклары да булды. Түзәргә өйрәндек. Әни хәзер төшкә дә сирәк керә. Бер генә теләк: йөзен онытмаска, тавышын хәтерләргә, әнине яңәшә тоярга кирәк. Ул безгә көч бирә, – ди.

Эльмира белән Эльвира Яңа Чишмә районының Тубылгы Тау авылында туып-үскән. Башта Түбән Камада яшиләр, аннан Казанга күчәләр. Инде әйткәнемчә, ирләре дә бертуган аларның.

– Абыемның Нариман исемле бергә хезмәт иткән дусты бар иде. Ул безгә кунакка кайтты. Ул чакта ирем булыр дип уйламадым да. Язмыштыр инде, без өйләнешергә булдык. Нариманның әтисе – казах, әнисе – татар. Алар мине сорарга өч тапкыр килде. Әти, бирмим, әле ул яшь, дип каршы килде. 21 яшемдә кияүгә чыктым. Аннан соң Эльвира Нариманның энесе Марат белән очраша башлады. Алар да өйләнешергә булды, – дип сөйли Эльмира. – Безнең өч ел балабыз булмады. Эльвира кияүгә чыгуга, бәбигә узып та куйды. Шунда ул мине гел юатып: «Табам да бу баланы сиңа бирәм», – дип торды. Әйтәм бит: бер-беребез өчен утка-суга керәбез без. Аның кызын үземнеке кебек яратам. Аллаһы Тәгалә миңа да әни булу бәхетен бирде. Мин малай таптым.

Эльмира белән Эльвирага табиблар башка бала табарга ярамый диләр. Инде нишләргә? Берсе – тагын бер кыз, икенчесе малай турында хыяллана. Эльмира белән Нариман тиз арада уртак фикергә килеп, ятимнәр йортыннан бәби алмакчы була. Эльмираның кешегә сиздерәсе дә килми әле. Янәсе, ике атналык бала ала да, үземнеке диячәк! Интернеттан һәр өч ай саен киеп була торган ясалма корсак та сатып ала. Шунда әтисе күктән җиргә төшерә аны. «Бар кешене дә алдап бетерә алмассың», – ди. Игезәк сыңарының ире башта бәби алуга каршы килә. Туганнары аны булачак әти-әниләр мәктәбенә үзләрен иярттеп алып китәләр. Марат бер дәрестән фикерен үзгәртеп кайта. Кайта гынамы соң, Нариман абыйлары кыз бала алганчы, малайлы да булып куялар. Шунысы гаҗәп: ике гаиләнең дә тәрбиягә алган сабыйлары нәкъ менә әниләренә охшап килә. Үз балалары исә йөзгә-биткә нәкъ әтиләре икән!

– Аллаһы Тәгалә күктә ул сабыйларны ничек итеп бүлә торгандыр инде. Нәкъ үзебезгә охшап торганы, туры килгәне әләкте бит. Ул балаларны алып кайткач, мулла чакырып, исем куштык. Әлегә алар тәрбиягә алынган икәнлекләрен белми. Чит кешеләр әйтеп, йөрәкләрен яралаганчы, үсә төшкәч, үзебез сөйләрбез, дип торабыз, – ди Эльмира.

Туганлык җебе

Бу гаиләдә ул бик нык. Өч сәгатькә сузылган аралашу вакытында шуны аңладым. Тыңлап-тыңлап торасың да хәйран каласың. Гаиләнең генә түгел, нәселнең үз тәртибе бар икән. Иң элек ике яшькә генә олы булган абыйларына карата хөрмәт зур. Әти-әнисе кызларны шулай үстергән. Кич клубка чыгасылары килсә, абыегыздан сорагыз, дигәннәр. Риналь сеңелләрен бик урамда йөртмәгән. Ә кызларның кич чыгасы килә. Алар хәтта әтиләренә рөхсәт сорап барсалар да, ул: «Абыегыз ничек әйтә соң?» – дип бора торган була. Әнә шулай итеп, абыйга зур хөрмәт тәрбияилиләр. Әле дә абый сүзе – закон. Нәселдәге бар абыйлар үз сүзен курыкмыйча әйтә монда. Әйтик, Ренат абыйның абыйсы аның балаларына нидер ошамауны, нәрсәгәдер хәтере калганны да килеп әйтә ала. Кызлар шундук гафу үтенә. Тагын бер гадәт: монда аерылышып йөрүчеләр бик сирәк.

– Гаиләдәге берәр күңелсез хәлне ишетсәләр, җыелыш җыялар. Бөтен нәсел белән сине яшәргә өйрәтәләр. Без моңа бик шат. Ни өчен сүзгә килгән, араны ничек җайларга була, барысын да хәл итәләр. Ир белән хатын арасын да көйләп куялар. Абыем улымны сүккәндә, мин дәшмим. Аның хакы бар. Бездә шулай, – ди Эльмира.

«Уртак йөрәк бездә»

Игезәкләр бер-береннән башка яши алмый, дигәнне еш ишетәбез. Ә бу йортта бөтенләй башкача. Бер карында ятуга дөрес тәрбия дә кушылган. Алар гел бергә. Башта туйлар уздырып, җырлап йөриләр. Тик тамада эшенең гомерлек түгеллеген, аны балаларыңа калдыра алмауны аңлый кызлар. Икесе бергә утырып киңәшләшәләр.

– Эльвира, кием кибете ачыйк, диде. Мин исә, чәчтарашханә, дим. Уйлаштык та «Цу-е-фа» уйнадык. Мин җиңдем. Шулай итеп, матурлык салоны ачылды. Хәзер без хатын-кызларны матурлыйбыз, – ди Эльмира. – Бер-беребезне ярату, тою хисе зур. Казанда янәшә йортларда яшибез. Эштә чакта күрше бүлмәдәге игезәгемнең хәле начарланганын сизеп алам. Кинәт кенә әчем поша башлый. Эльвира янына керсәм, аның кан басымы күтәрелгән икән. Кайчак иртән йокыдан уянуга хәл юк, әллә нинди авырлык бар. Яшьрәк вакытта тизрәк дару эчәсең, кан басымын үлчисең. Еллар уза торгач, сәбәбен белдек без аның. Баксаң, йокыдан торуга, игезәгеңә шалтырату кирәк икән. Бер сөйләшеп алуга, бар да җайлана. Мин гел Эльвира ышыгында яшим. Ул мине саклап-яклап тота. Берәрсе бер сүз әйтсә, ул хәл итә. Мин шулай өйрәнгән инде. Артык йомшакмын. Игезәгемә чиксез рәхмәтлемен. Ансыз мин бер көн дә тора алмыйм.

Кайсыгызның кулы җылы?

КОЛЯСКА КИРӘК!

Исәнмесез, хөрмәтле редакция! Газета укучыларга зур үтенечем бар иде. 7 ел инде авыру бала үстерәм. Көтеп алган улыбыз җитлекмичә туды. Табиблар ДЦП диагнозы куйды. Сабыемны кая гына йөртмәдек. Төрле дәвалау курслары үттек. Кечкенә чагында аны күтәреп йөртү дә җиңел иде. Без улыбыз аякка басар дип өметләндек. Тик булмады.

Хәзер инде балам үсеп китте. Авырайды, күтәреп йөрү кыенлашты. Аны йөртергә махсус коляска кирәк. Үзебезнең коляскабыз бар безнең. Әмма аның белән авыл урамнарында йөреп булмый. Нәкъ менә безнең диагнозлы балалар өчен махсус ясалганы бар икән. Шуны алмакчы идек. Әмма үз көчебез генә җитми. Интернеттан эзләп таптык, иң арзаны 148 мең сум тора. Без акча җыеп бетергәнче, бәясе дә күтәрелергә мөмкин. Шуңа да мәрхәмәтле кешеләрдән ярдәм сорыйм. Булышсагыз иде.

Рузилә МИҢНУЛЛИНА. Арча

Булышырга теләүчеләр өчен: Рузилә Зөфәр кызы Миңнуллина исемендәге Саклык банкы картасы 89196852830 номерына беркетелгән.

СОЛДАТ РӘХМӘТЕ

Энем унынчы аен махсус хәрби операциядә катнаша. Җае чыккан саен, аралашып торабыз. Шушы көннәрдә сөенеп шалтыратты. Татарстан егетләре күчтәнәчләр алып килгән икән. «Рәхәтләнеп чәкчәк белән чәй эчтек. Өйгә кайткандай булдым. Күзләремнән яшь чыкты хәтта. Пешереп җибәргән апаларга мең рәхмәт», – ди. Шул сүзләрне сезнең газетагыз аша солдатларга чәкчәк пешергән кызларга җиткерәсе иде.

Гөлнара ДӘҮЛӘТБАЕВА. Башкортстан

kzn.ru

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЗИФА НАГАЕВА: «БЕР-БЕРЕБЕЗНЕҢ ХАКЫН ХАКЛЫЙ БЕЛМИБЕЗ»

Җырның ертыгы була. Сүз һәм гамәл һәрвакытта да туры килеп бетми. Шәхес кадере шәхеснең үзеннән башлана. Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Зифа НАГАЕВА белән менә шундый четерекле темаларга сөйләштек.

:: Зифа апа, көнне ничек башладыгыз?

– *«Мин кем!» диеп күкрәк какмыйм,*
Кагарым – йөрәккенәм!
Ул кагарда төшәр таудан
Биек үрләргә менәм!» –

дип, шигырь язып утырам әле. Өстәл тулы каралама, ничәмә-ничә төрле вариантын эшлим. Күңелнең шигырь белән мөлдерәмә чагы.

:: «Мин кем?» дигән сорауга ничек җавап бирерсез?

– Кан белән килгән вазыйфам – әни һәм нәнәй булу. Ә инде халык өчен мин – Зифа Нагаева. Моңа барысы да сыйган: үзем, халәтем, моңым, телем.

:: Күп кенә җырчылар сезнең җырлар белән танылды. Алар хәзер сезне кадерлиләрме? Авторлар бик күп чарада «төшеп» калганга, онытылганга сорабым.

– Бәкәлгә суккан сорау бу. Үстереп җибәргән җырчылар арасында очар канатларын кайдан алганын тоемлап яшәүчеләр дә бар. Шул ук вакытта үсенеп китеп, башларына таҗ киеп алганнары да юк түгел. Түбәтәй кисәләр, акыл булыр иде, калфак кисәләр, татар булыр иде, дип елмаеп күзәтәм инде мин аларны. Исемнәрен әйтмим, ник дигәндә, исемнәрен ишетсәләр дә, минем хакта әйтәдер дип уйламаячаклар. Чөнки алар бу дулкында уйлый белми, алар инде күктә, биеклектә. Алай да, әллә кемдер башларына сугып аламы – юк-юкта шалтыратып, хәл белешеп алырга мөмкиннәр. Ләкин бу – вакытлыча күренеш. Хәер, мин аларга аптырамыйм, үпкәләмим дә, күзәтәм генә. Бер караганда, «йолдыз»лыкның чиргә кадәр барып җитүе моңсу, әлбәттә. Ул бичара күктән ни сәхнәгә төшеп җырлый алмый, ни күңеле белән халык арасына сыешмый. Андыйлар, автор күбрәк процент ала күрмәсен дип, исемне атамас өчен ниләр генә кыланмый. Шулар арасында авторларны һәр чыгышларында искәртүчеләр, социаль челтәрләрдә таратучылар да бар. Хәер, мәнле кешеләр барыбер күбрәк. Фән Вәлиәхмәтов, Зөһрә Шәрифуллина, Зәйнәп-Зөфәр, Зөлфия белән Җәвит, заманында Хәния Фәрхи – әнә шундыйлардан. Авторны зурлаганнан бервакытта да абруйлары төшмәде, күтәрелделәр генә.

> *Бер көнлек җырларга күчтек, шунысы аяныч. Пентатоника бетте. Матур сүзләрне рус көенә салып утырган аранжировщиклар басты дөньяны. Элек композитор дип танылган кеше (ул консерваторияне тәмамламаска да мөмкин) чын талант иясе, самородок була иде. Хәзер композитор дигәне дә аранжировщикка әйләнеп бара.*

:: Татар-башкорт эстрадасы ни хәлдә?

– Җырчыны халык күтәрми, җырчы үзен үзе күтәрә хәзер. Бу җәһәттән башкорт эстрадасы тыйнаграк түгелме икән әле. Башкорт эстрадасында моңлы көйләргә урын бар. Биредә халык бәя биргәнне көтә беләләр. Тыйнаграк. Татарстан эстрадасы бу җәһәттән шау-шулырак.

:: Эстраданың өмете дип кемнәрне атар идегез?

– Өмете дип әйтерлекләренең сәхнәгә чыгу өчен этәргечләре юк. Менә шул йөрәкне әрнетә. Радиода бик күп еллар эшләгәч, мин моны яхшы беләм. Минем «Бер вакыт кына» җыры җырланган заманда әле кеше моңы белән чыга ала иде. Хәзер моңны акча дигәнең төртеп екты. Синең янында яхшы продюсер булу, җырларыңны раскруткага бирү кирәк. Менә мин билгеле композитор булсам да, Татарстанга шалтыратып, матур җыр язган идем, клибым да бар, дип авызымны ачсам, аны шунда ук бәяләр язылган прайс-лист белән томалыйлар. Акчам бар, түли дә алам. Ләкин миңа раскрутка кирәкми, миңа халыкның җырларымны ишетүе кирәк. Бу яктан караганда, Башкортстанда әле «Шәрык» радиосында, «Юлдаш»та исемнәр дә әйтелә, авторлар хакы да хаклана. «Юлдаш» дәүләт радиосы булып калды һәм анда бөтен нәрсә дә акчага көйләнмәгән.

Һәр композиторның үз стиле бар. Бу – бервакытта да модадан чыкмый торган нәрсә. Стиль кала, аңа яңалык өстәлә, нәтиҗәдә матур әсәр туа. Әмма бит эфирда күбрәк «тыкы-тыкы». Истә дә калмый инде ул, бер тыңларлык кына. Менә шушылар сыйфатны басып китте. Алай да өметле яшьләр бар. Андыйлар гадәттә сүзгә, көйгә, үз-үзенә таләпчән була. Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар, Алинә – Азат Кәримовлар, Ранис Габбасов, Марат Шәйбәков үрнәк. Болар үз дәрәҗәләрен белә, халыкны тәрбияли, «тыкы-тыкы»лар кебек шашынмый. Аларга микрофон да кирәкми хәтта, гармунга кушылып җырласалар, шул да җитә, күңел була. Менә шундый җырчылар безне дә илһамландыра. Бу фикерне әйткәч, кайсылары, без бит яшьләр, безгә башкача кирәк, диләр. Ярар, бер аңларсыз әле, дим, сүз көрәштермим. Сүз уңаеннан, Руслан Кираметдиновны да яратам. Әмма ул кеше җырлап күрсәткән җырларны ала. Ә бит аның тавышы белән таулар актарып була. Сәләтне Ходай ишеп биргән үзенә юкса.

:: Сезнең тапшыруларда геройлар эчсерләре белән бүлешә. Әгәр үзегез шул тапшыруларның берсендә герой булсагыз, тормышыгызга нинди бәя бирер идегез?

– Адәм баласы, олыгайгач, үткәннәр белән яши башлый. Әйе, сагыну тулгаклары күп, әмма үткәннәр белән генә яшәргә ярамый. Әйтик, без барыбыз да авылыбызны, туып-үскән нигезебезне сагынып яшибез, шушы сагынуны җырларга салабыз. Аннары ул юксынуларга югалту ачылары өстәлә. Әле узган көздә генә бертуганымны җирләдем. Гаиләдә икәү генә идек, бик зур югалту, фаҗига булды минем өчен. Әмма бу сагынулар, юксынулар белән генә яшәргә, ул кысаларда гына калырга ярамый. Шуның өчен туган авылыма кайтып төпләндем, йорт салып чыктым, урманнарым, бәләкәй чакларда йөргән сукмакларым белән хушланам, актив яшәү рәвеше алып барам. Кайчакта хәл дә булмый, алай да үземне кулга алам һәм һәр иртәдә велосипедта йөреп керәм. Иртән уянганмын, балаларым хәбәр биреп алган икән, шөкер итәргә, заман белән бергә атларга рух һәм тән сәламәтлеген кайгыртырга кала. Авыруларга юл куйсаң (ә миндә алар җитәрлек) бетәсең дә китәсең инде. Гәрчә бик күп авырлыклар, аерылу-каерылуларны кичерсәм дә, үкенечем берәү генә: әниемне түгәрәк дөньямда түремә утыртып хөрмәт күрсәтергә чак кына вакыт җитми калды. Дөрес, ул радиода эшләгән чакларымны, беренче уңышларымны күрде, әмма барыбер кадерләп җиткерә алмадым кебек. Бүген нәрсә киясе килсә, шуны алыр идем, алар бит юклык заманында яшәделәр, нәрсә ашыйсы килсә, шуны алларына тезәр идем. Кайсы илгә барасы килә, шунда алып барыр идем... Менә шунысы – үкенеч. Минем тормышым гөрләп бара, бәхетлемен. Бәхетсез дисәм, аяз көндә яшен сугар. Чөнки мин үземнең заманымда вакытны кулымнан ычкындырмадым. Әле тагын да эшләрмен, өлгерермен. Мин кешелеккә кирәкле булдым, моны булдыра алдым. Бу – зур бәхет. Менә шушы булмышым бөтен сагышларымны каплый. Ләкин әни үкенече мәңгелек, үзем киткәнче булачак. Үземә матур кием алсам да, их, әнигә дә кидертәсе килә. Алдымда тәмле ризык булса да, әни белән бүлешәсе килә. Булмый шул. Ә кешелеккә минем бирәселәрем күп әле. Иҗат куәсләре тулы булганда, эшләргә дә эшләргә әле. Аласымны түгел, һаман бирәсемне уйлыйм.

> *Иң курыкканым – кешеләр белән аралашудан мәхрүм булу. Мин кешесез тора алмыйм. Пандемия чорында, бөтен халык бикләнеп ятканда, кызым, битлек кидереп, тәзелеш кибетенә алып барды. Алар нидер сорый, дәшә, ә мин ишетмим икән. Мин кешеләр карап йөрим. Бүтән җирдә кеше юк бит. Менә шундый инде мин.*

:: Интервьюларда, гадәттә, олыгаю яки өлкән буын турында сүз чыкса, кадерли белмәделәр, бездә шәхес кадере юк, дигән фикергә килеп төртеләсең. Ә бәлки кадерсезлеккә сәбәп тә үзеңдәдер?

– Кадерсезлекнең төрле ягы бар. Элекке заманда язучылар, композиторлар сирәгрәк булган. Менә алар бер-бер артлы китеп бара. Ринат Еникеев, Рамил Курамшин, башкалары. Аларны озатырга билгеле бер кечкенә генә төркем йөри, каберләренә чәчәк сала. Яшьләргә бу кирәкми. Бусы – бер. Инде икенче яктан карасак, әйтик, менә мин исән чакта үземне үзем кадерләргә тиеш. Миннән соң тарихта ни кала? Бу сорауны үземә еш бирәм һәм иҗат белән дә, көндәлеккә теркәп тә җавап биреп калдырырга тырышам. Без глобаль проблемалар заманында яшибез. Шулар арасында иң кискен торганы – тел мәсьәләсе. Мин башкорт илендә татар булып яшим һәм кайбер мәсьәләләрдә аның хәйләкәрлекләрен дә аңлыйм. Әмма мин татарны аңламыйм. Соңгы елларда бигрәк тә. Исемнәр ала башлагач, бу галәмәт тагын да калкып чыкты. Юкса

Блиц сораштыру

– Из зур теләгегез нинди?
– Һәр көнне, җыр канатларымны сындырма, кешеләрдән аерма, кешелеккә кирәкле булып яшәү бәхетеннән мәхрүм итмә, саулыкта яшәргә насыйп ит, дип телим.

– Кешедәге иң начар сыйфат кайсы?
– Икейөзлелек.

– Иң яхшы сыйфат?
– Ихласлык.

– Сезнең турында фильм төшерсәләр, ул ничек аталыр иде?
– «Кем мин?»

мин бары тик тырышып эшләдем, көн дә эфирга бардым, иҗат иттем. Татарның бер-берсеннән көнләшкәнен аңламыйм. Юкса бер казанда кайныйбыз бит. Юк, әллә кем булмасын дип, башка сугу, кагу кирәк. Бердәмлекне без милләтләр арасындагы татулыкта эзлибез. Ә бит үзебезнең арада да татулык бетеп бара. Бер-беребезнең хакын хакларга, күрергә, үстерергә, халкына гомерен багышлаган икән, ул кешене тарихка әзерләргә кирәк. Ә татар зыялыларының хәле бер-берсе белән көрәшеп бетә.

:: Балаларыгыз, оныкларыгыз татарча сөйләшәме?
– Бөтен проблема татарча сөйләшүгә генә кайтып калмаска тиеш, җаның татар булсын. Әле татар теленең хәле мондый кискен тормаганда да, татар түрәләренең балалары чит илдә белем алды. Хәзер инде тел дип күкрәк каккан булабыз да, соң инде дип җырларга гына кала. Соңгы мәхәббәт кебек килеп чыкты бу. Кызымның ире – шәһәр егете. Әнисе – поляк милләтеннән, атасы – башкорт, минем кызым – татар. Болар бер дигән балалар үстерә. Хәлдән килгәнен эшләсәк тә, «бытовуха»дан уза, Тукай шигырьләрен ятлата алмыйм шул. Татар мәктәбе калмады бит инде. Татар балалар бакчалары да калмады. Инде соңга калдык. Улым гаиләсен алсак, киленем – башкорт. Күпме булдыра алам, татарлыкларын сакларга тырышам. Балаларым татарча шытырдатып сөйләштеләр, ә оныклар белән шушы хәл. Иманнары нык булсын. Бездә монда иртән кызыл яулык бәйләп, кичкә агына алмаштыручылар да байтак. Бөтен җирдә нинди дер модага иярү китте. Хәтта мәчетләрдә дә хәлләр шулайрак. Яңадан клубка әйләнә түгелме иман йортлары? Никах мәҗлесләре шунда үтә, артистлар килеп, җыр җырлап китә. Урыны шулмы аның? Ләйлә Дәүләтова никах мәҗлесләренә артистларны чакырмаска кирәк дип язып чыккач, барып үбәрдәй булдым үзен. Еш кына нәрсә кыланганны үзебез дә аңлап бетермибез кебек.

:: Сәхнә ул – нинди җир? Кеше көлдерәм дип сүгенүләр, анекдот сөйләүләр килешәме анда?
– Тикмәгә генә сәхнәне җирдән күтәртеп ясамаганнар бит инде. Димәк, анда чыккан кеше халыктан олырак, камилрәк, көчлерәк булырга тиеш. Шуңа күрә мин болай дип әйтәм: халык каршына чыккансың икән инде, телеңә ни килде шуны сөйләмә, зыялылыгың белән булеш. Җитте заман: бер артист төкеренә дип, икенчесе төкеренә башлый. Шуннан кызык табып, пародия ясыйлар. Сәхнәгә менәрлек аң-дәрәҗәң юк икән, халык арасында утыр, алардан өйрән башта, аннары гына тәвәккәллә. Сәхнә ул – бөек урын. Биегрәк эшләнгәнгә генә түгел.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 14, 21, 28 июль, 4 август саннарында

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА

ТУЗГАНАК КЕРФЕГЕ

Бераздан инде дөнья ачысын онытырга да өлгергән кызлар, туңган аякларына җылы эзләп, сызыклы да уйнап алдылар, аннан, кибәргә дип аударылган кирпечләр янына килеп, шул тирәдә әрле-бирле йөренделәр. Менә Асия шул кирпечнең берсе өстенә менеп тә басты, кулларын чәбәкләп кычкырып та җибәрде:

– Әл-ләй, җылы, Гөлсәй!

Озын итәге белән тезләрен каплап, чирәмгә чүмәшкән Гөлсәйдә дә сикереп торды, ул да, ялан тәпиен кирпечкә тигерүгә, сөенечтән чыркылдап куйды.

Һәр кирпечкә икешәр аяк эзе төшерә-төшерә, рәхәтләнде генә кызлар: яңа шөгыль дә таптылар, җылынып та киттеләр. Кирпечләрнең байтагын таптап, бармак эзләренә төртеп көлешкән арада әбәдтән әниләре дә килеп җитте.

– Әннәче, булдырганнар бит болар! – Бүтәннәрне авызына каратып, ниндидер кызык сүз сөйләп килгән Мәрфуга, капыл бүленеп, учы белән ботына шапылдатты.

– И Алла, эш өстенә эш ясамасалар! – Нәсимә Асиянең сөяктән генә торган кулыннан йолкып, читкә тартты да: – Шуны гына белмәслек түгел бит инде сез, җан көекләре! – дип, йодрыгы белән кызының иңбашына төртә-төртә битәрләргә тотынды.

Асия, әллә авыртудан, әллә гарьлектән, күзләрен чытырдатып йомып, бар көченә үкерә башлады. Гөлсәйдә дә, ниндидер ярамаган эш эшләүләрен аңлап, мыштым гына әнисенең итәгенә артына яшеренде.

Хәдичәнең беркайчан да балаларына кул күтәргәне юк иде, бу юлы түзмәде, дык итеп кызының аркасына төртеп алды да:

– Башкайларың юктыр инде синең, и бала! – диде әрнүле тавыш белән.

Кибәргә дигән кирпечләрнең шактые яраксызга әйләнгән иде, хатыннар, ярты көнлек хезмәтләренең җилгә очканын күреп, аһ та ваһ килделәр. Арада иң өлкәне булган, төпле акылы, аз сүзлелеге белән аерылып торган, уң күзенә ак тошкәннән кимсенепме, кеше күзеннән гел читтә торырга яраткан Сәлимә, балаларны кызганып:

– Ярар, каш ярылып күз чыкмаган, төнгә кадәр ничек тә нурмыны тутырырбыз әле. Мирхәт тәре генә исңәнеп йөрмәсен... – дип әйтеп тә бетермәде, тыкрык буеннан төшеп килгән бригадирны шәйләгәч, өметсезләнеп кулын селтәде.

Якты көнне куркытырга җыенгандай, кап-кара озын плащ, фуражкага тартым кара кәпәч кигән Мирхәт, гадәтенчә, сул кулын кызу-кызу селтәп, хатыннар янына килеп тә җитте, аяк эзләре җәйрәп яткан кирпечләргә пычрак бармагы белән төртәтөртә:

– Бу нәрсә? Нәрсә бу дим мин сезгә? – дип гырылдавык тавыш белән җикеренергә дә тотынды.

Асия белән Гөлсәйдә әниләреннән куркуны онытып, шушы килбәтсез чырайлы адәмгә текәлеп катканнар иде. Хәдичә, ни булса шул булыр дип:

– Куярга урын булмагач, менә ияртеп йөрибез, бала-чага тик тора беләмени ул, эш ясап куя, – диде, кызларга ымлап. Аннан, башын югары күтәреп: – Балалар бакчасы ачыйк дип кайчаннан әйтәбез. Өйдә утырып, ут-күз чыгаргалы бар. Мәктәпнең бер башында бакча ачсак...

Сүзен тәгәлли алмады, Мирхәт аның каршысына ук килеп басты да, туктаусыз йөгерешеп торган күзләрен түгәрәкләндерергә тырышып:

– Яп авызыңны, кулак калдыгы! Өйрәтеп тора ишшу... Үзеңнең генә бридетель булуың җитмәгән, балаларыңны да сәвиткә каршы котыртып үстерәсең, ә! Икегезне дә районга илтеп яптырам мин сезнең! – дип, Хәдичәнең беләгенә килеп тотынды.

– Канатларыңны җәймә, бригадир булдым дигәч тә... – Гомер булмаганны, Хәдичәнең корыч тавышы һаваны ярып үтте, ул, каты селтәнеп, Мирхәтнең кулын читкә атты.

Шулвакыт кыр казлары урынына каңгылдашкан хатыннар арасыннан Мәрфуга алгарак атлады, арттан чөеп бәйләгән яулыгын башыннан сыдырып алды да җан әрнүе белән лып итеп җиргә утырды.

– Нигә аларны гына ди, безне дә илтеп яптыр. Ичмаса, бу кәтер эшеннән котылып, бер-ике көн булса да ял итеп кайтырбыз! – Хатынның бераз шадраррак йөзе күтәралмас йөк авырлыгыннан җыерылгандай, гармун күрегенә охшап калган иде. Ул, алдында ир заты басып торуга да карамастан, озын итәген җыера төшеп, аякларын җәеп куйды да бөтенләй көтмәгәндә уенчак тавыш белән җырлап җибәрде:

Сания апа суга бара
Яшел чиләген асып.
Сандугачлар чут-чут сайрый
Көянтәсенә басып...

Мирхәт әле дә булса әнкәсе итәге артында посып торган Гөлсәйдәгә йодрык күрсәтеп:

– У-у, эт баласы! Монысы да бүре кебек карап тора бит аның! – дип аяк астына черт итеп төкерде дә аннан Мәрфугага борылды. – Нәрсә монда җәмиләнңе җәеп утырасың, сез браковать иткәнне әллә мин килеп эшләр дисеңме? Себерелеп йөрергә беләсез.

Дәвамы бар >

Белдерү

КОМПЛЕКСЛЫ КАДАСТР ЭШЛӘРЕН БАШЛАП ҖИБӘРҮ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ

2023 елның 7 июленнән 2023 елның 15 ноябренә кадәрге чорда Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге адрес буенча урнашкан күчемсез милек объектларына карата: Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, 16:33:080303, «06.03.2023 ел, № 923000033-ОК» Дәүләт контрактына үзгәрешләр кертү турында» 07.07.2023 ел, № 1 Өстәмә килешү нигезендә, комплексы кадастр эшләре башкарылачак. Заказчысы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, почта адресы: ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й., телефон: 8 (843) 221-40-60.

1. Комплексы кадастр эшләрен башкаручы кадастр инженеры: ФИО: Мөбарәкшин Рамил Наил улы. Адресы: 422060, РТ, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Мотыйгуллин ур., 24 й. Почта адресы: filial@16.kadastr.ru. Телефоны: (843) 514-90-77 (2272). Идентификация номеры 16-11-289, 2011 елның 14 мартында бирелгән.

«АКИ Поволжье» үзкөйләнешле ассоциациясе әгъзасы булып тора, реестрда – 0153. Дәүләт контракты төзелгән, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалы хезмәткәре.

2. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 4 өлеше нигезендә элек исәпкә алынган дип саналган яки аның турында мәгълүматлар «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында күчемсез милекнең мондый объектлары турында мәгълүматлар булмаган очракта, элек исәпкә алынган буларак Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертергә мөмкин булган күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына – комплексы кадастр эшләрен башкаручыга мондый күчемсез милек объектларына карата үзендә булган материаллар һәм документларны, шулай ук «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 21 статьясындагы 1 һәм 9 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә расланган, әлеге күчемсез милек объектларына хокукны билгеләүче яки раслаучы документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы.

3. Күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң утыз эш көне эчендә 1 пунктта күрсәтелгән кадастр инженерына – комплексы кадастр эшләрен башкаручыга комплексы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 2 пунктында күрсәтелгән, күчемсез милек объектына хокуклы булуы теркәлгән зат белән элемтәгә керү өчен электрон почта адресы һәм (яки) почта адресы турында мәгълүматлар күрсәтелгән адрес буенча – күчемсез милек объектына хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук үз файдасына күчемсез милек объектына карата чикләү салынган зат белән элемтә алып барыла торган – объект хуҗасының элемтәгә керү өчен адресы турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен һәм мондый затларга комплексы кадастр эшләре нәтиҗәләре буенча территориянең карта-планы проектын әзерләүне тәгәлләү турында һәм җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында мәгълүматларны тапшырырга тиеш.

4. Комплексы кадастр эшләре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектлары хуҗалары комплексы кадастр эшләрен башкаруга комачауламаска тиеш, һәм алар комплексы кадастр эшләрен башкаручыга билгеләнгән вакыт графигы нигезендә аның әлеге күчемсез милек объектларына үтүен тәэмин итүгә бурычлы.

5. Комплексы кадастр эшләрен башкару графигы

№	Комплексы кадастр эшләрен башкару урыны	Башкару вакыты
	Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, 16:33:080303	07.07.2023 – 15.11.2023

МИН СИНЕ ЯРАТАМ

- **Абхазча** – Сара бара бзия бзо
- **Алтайча** – Мэн сэни турар
- **Әрмәнчә** – Эс кэс сирумэм
- **Белорусча** – Я тябэ кахаю
- **Бурятча** – Би шамай дурлаха
- **Грузинча** – Ме шен миквархар
- **Казахча** – Мэн сэни жаратам
- **Калмыкча** – Би чи дурта болх
- **Коми** – Мэ радэйт тэне
- **Кумыкча** – Мэн сэни сюйим
- **Латышча** – Эс тэви милу
- **Литвача** – Аш тавя милю
- **Ненецча** – Мань хамзангав сит
- **Осетинча** – Аз даима уварзон
- **Хакасча** – Мин син хынара



Әз-мәз мәзәк

Безнең завод быелдан төрле диаметрлы торбалар җитештерә башлый. Төрле диаметрлы беренче торба конвейердан инде августта ук чыгарга тиеш.

* * *

Миңа бөтен туганнарым бай ир тели. Нәрсәгә миңа бай ир? Байлык теләгез миңа. Мин һәм байлык арасында миңа арадашчы кирәкми.

* * *

Әгәр дә хезмәткәрләр начальникнең шаяруларыннан көлми икән, димәк, тиздән җитәкчелек алышына, дигән имешмимеш узган.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Мокамай, Яуширмә, остаз, Ык, разый, но, кул, шәмдәл, ризык, ре, ул, ата, Шамил, ахмак, за, бар, Мисыр, Уразмәт, ятка, ук, үләт, ас, илче, иҗат, Әнисә, уян, ир, бәк, оят, Ялт, Әпипә, Астра, Данил, антивирус, каравыл.

Вертикаль: Мамадыш, Якубович, Әсхәт, Кино, дуамал, Әлки, чит, суер, йодрык, анык, Айдар, урт, иблис, утыз, Лиаз, үҗәт, Тунис, акын, Аулак, яр, яз, йомыш, рәт, ачлык, кабат, МАЗ, әни, Ширмән, илә, Стас, Әлдермеш, Сәрбиҗамал.

Беләсең килсә...

1 Юмор остасы Михаил Галустянның чын исеме нинди?
а) Ишан;
б) Ншан;
в) Мшан.

2 Кошлар көне Россиядә кайчан билгеләп үтелә?
а) 1 апрель;
б) 1 май;
в) 1 сентябрь.

3 Кайсы планета Кояшка якынрак?
а) Плутон;
б) Сатурн;
в) Меркурий.

4 Дөянең өркәчләрендә нәрсә урнашкан?
а) су;
б) мускул;
в) май.

Җаваплар: 1.б); 2.а); 3.в); 4.в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 314

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрриренең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+